Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 35 (1400) 9 сентябрь 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

2

Туймазы төбәгендә татар рухын саклау һәм ныгыту өчен эшмәкәр Фәнир Галимов бар күңелен һәм мөлкәтен биреп көч куя.

14

Атаклы сәясәтче Уинстон Черчилльне без дәүләт башлыгы дип кенә беләбез, ә ул танылган әдип тә, оста рәссам да була.

16

Аяусыз репрессияләр ташкынына бик күп күренекле, иң алдынгы татар хәрбиләре эләгә.

Гасырлардан гасырларга җилеп Ил корышкан татар атлары!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстанның Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиле Ренат Вәлиуллин «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде.
- «Созвездие-Йолдызлык» арт-резиденциясе быелгы сезонын А.С.Пушкин исемендәге мәдәният үзәге сәхнәсендә Гозәер Хаҗибәковның «Аршин мал алан» музыкаль комедиясе белән ача.
- Уфада Флорид Бүләковның танылган пьесасы буенча башкорт телендә төшерелгән «Әбиләр чуагы» тулы метражлы нәфис фильмының премьерасы булды.
- «Казан утлары» китапханәсе сериясендә унбишенче китап булып, Рафис Корбанның «Тәүбә көне» дип исемләнгән җыентыгы чыкты.
- «Казан Кремле» музей-тыюлыгында шәһәрнең Җәмигъ мәчетләренә багышланган фотокүргәзмә ачылды.
- Идел Болгарында ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан Саратовта яңа мәчет төзелә башлый.
- Габдулла Тукай әдәби музеенда шагыйрьнең Троицк шәһәренә баруына 110 ел тулуга багышланган «Тукай Троицкида» күргәзмәсе эшли башлады.
- Г.Камал театры артистлары һәм музыкантлары Казанның Толстой урамындагы бер йорт янында «Безнең ишегалды: тарих һәм хәзерге заман» дигән бәйрәмдә чыгыш ясады.
- Россиянең төрле төбәкләреннән һәм якын чит илләрдән 50 дән артык рәссам Әгерҗе районының Красный Бор авылында пленэр уздырды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Рифә РАХМАН, шагыйрә:

«Чын матур сөйләм тирәлектә аз яңгырагач, кеше нормалар кысасына кергән телгә кайдан өйрәнсен?! Ул лексик ярлы һәм хаталы аралашуга күнегә. Аны «заманча» дип аклый, хаталы сөйләмне, шуңа нигезләнгән әдәбиятны табигый саный башлый. Күпләр сөйләмнәренең җитешсезлеген тоймый да!»

СЫНАМЫШЛАР

Сентябрьдә яшенле яңгырлар еш яуса, көз җылы килә ●Симән көнне (искечә 1 сентябрь – яңача 14 е) җылы булса, бөтен көз җылы була ●Симән көнне күк күкрәсә, көз озакка сузыла, киләсе елда ашлык уңа ●Симән көнне яңгыр яуса, көз пычрак килә ● Көзен каен агачлары астан саргаеп, яфракларын астан коя башласа – кыш җылы килә, ә өстән саргаеп, өстән яфрак коя башласа – кыш салкын килә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 03 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 17 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **13 сәгать 14 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **16 сентябрьдә 12 сәгать 43 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

10 сентябрь – актер, режиссер, Татарстанның атказанган артисты Шакир Габделгани улы Вахитовның (Шамильский) тууына 130 ел (1892–1945).

11 сентябрь – актёр, режиссёр, педагог, Татарстанның халык артисты Касыйм Шамил улы Шамилнең тууына 130 ел (1892–1981).

15 сентябрь – драматург, артист һәм режиссер Кәрим Гали улы Тинчуринның тууына 135 ел (1887–1938);

– журналист, шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Асия Шәйхразый кызы Юнысовага 75 яшь (1947).

12 сентябрь – шагыйрь Сафуан Галәветдин улы Муллагалиевнең тууына 95 ел (1927 –2008).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 10, 13 сентябрь.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(10-18 сентябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген сәфәр аеның 13 нче көне

ТУЙМАЗЫ – ТАТАР ИЛЕ

Безнең узган елдан бирле Башкортстанның төрле төбәкләренә сәяхәт кылуыбыз турында ишетеп алгач та, Туймазы һәм шаранлылар да, аеруча Октябрьский каласыннан Адилә ханым, кат-кат шалтыратып, үзәкләргә үтте:

– «Мәдәни җомга» газетасына гына да егермедән артык кеше язылдык бит, сез кайчан безнең якка да килеп чыгасыз соң?

Ниһаять, август аеның соңгы көннәрендә, тәвәккәлләп, бу төбәккә дип тә юлга чыктык. Иллә мәгәр аңа кадәр Лениногорск, Азнакай, Ютазы районнары, Урыссу, Октябрьский калалары аша да үтеп китәсе бар. Мин фәкыйрегез Туймазыны 40 ел чамасы элек күргән идем. Телисеңме-юкмы, юлда бутала-бутала, урый-урый интегергә дә туры килә икән.

Әмма барып җиттек. «Татар үзәге» дигән сүзне яки Фәнир Галимов исемен ишетүгә үк, Туймазының һәр урамында диярлек ориентирны дөрес күрсәттеләр. Ульяновлар урамы чатында алдына Тукай бюсты куелган үтә затлы йортны шәйләп алгач, килеп җиткән булуыбызны чамаладык. Урамның бер ягында – бөек шагыйрь бюсты, аның артында Былтыр белән Шүрәленең агачтан юнып ясаган һәйкәлләре. Икенче якта – бер Туймазыга гына түгел, ярты Рәсәйгә мәгълүм «Илфа» берләшмәсенең төп базасы. Фәнир Галимов белән 25-30 ел элек үк танышкан булсак та, аны электр челтәрләрен яңарту һәм төзекләндерү буенча илкүләм әһәмияткә ия берләшмәнең генераль директоры дип күз алдына китергән юк иде. Бактың исә элекке ил генә түгел, ә андагы барча сәнәгать челтәре һәм элементләр таркала башлагач, Фәнир әфәнде үзенең дусты Илшат белән Туймазыдагы электр белән тәэмин итү оешмасын үз кулларына алган да «Илфа» атлы предприятие төзеп куйган икән. Хәзер, әнә, аларның белгечләре Норильск, Наманган, Сургут, Төмән төбәкләрендә линия яңарта, иртәгә Курган өлкәсенә күчүләре мөмкин. Уйлап куям: әле ярый Фәнир «Башэнерго» идарәсенә яки Башкортстан хөкүмәтенә буйсынмыйча яши, киресенчә булса, аны татарлыгы өчен әллә кайчан кәнәфиеннән бушатырлар иде.

Нәкъ производство идарәсе каршындагы буш урынга йөзен Тукай бюсты бизәгән, ә үзе өч катлы үтә затлы татар иҗтимагый үзәген төзеп куй әле! Подвалында «Тәртип-FM» радиостанциясе, өске ике катта иҗтимагый үзәк, китапханә, балалар һәм өлкәннәр җыелу өчен аерым,

● Без кунаклар белән «Бабай утары»нда.
Сулдан уңга: Р.Сәгъди, В.Имамов, А.Дәүләтшин, М.Галиев, Ф.Галимов.

шәп бүлмәләр, «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы, музыкаль үзәк, музей, киңәшмәләр залы... Йә, әйтегез, безнең Татарстанда моның белән чагыштыра алырдай иҗтимагый үзәк калдымы да, бездә Фәнирдәй татар җанлы эшмәкәр бармыни?!.

Янәшәмдә сәяхәткә чыккан Марсель Галиев, Рәдиф Сәгъди белән безне Фәнир бүлмәсендә чәй белән сыйлый башлаганнар иде инде, ниндидер производство эшләреннән бушап, хуҗа үзе дә кайтып керде. Бераздан Тукай бюсты янына Туймазы гына түгел, ә күршедәге Шаран, Бәләбәй, Октябрьский, Ярмәкәй районнарыннан да иҗтимагый үзәк һәм әдәби берләшмә җитәкчеләре җыела башлады. Бигрәк тә Уфа каласыннан Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле Альфред Дәүләтшинны һич көтмәгән идек, ул да килеп җитте. Иҗтимагый үзәк залында Башкортстанның бу төбәгендәге татар проблемалары турында озаклап сөйләштек.

Бер уйласаң, безнең өчен көтелмәгән яңалык юк шикелле. Туймазы районында – 90 меңнән, Бәләбәй янында 30 меңнән артык татар яшәсә дә, Башкортстан мәгариф министрлыгы уку программаларына башкорт телен кертмәүче мәктәп коллективларын «үтүкли», татар телен – дәүләт теле буларак һәм Татарстан юллаган дәреслек белән методик кулланмаларны бусагадан кертмәскә тырыша. Шул ук вакытта, әнә, Бәләбәйдә 1930 елларда ук ачылган һәм анда Фатыйх Кәрим, Мәгубә Сыртланова... кебек күренекле шәхесләр белем алган педагогика техникумын, бинасына ремонт кирәк дигән сылтау табып, ниндидер механика техникумы белән кушып куярга җыена. Ремонт дигән сылтау янына балалар укырга килми, студентлар җитми, дигәнен дә өстәп куярга мөмкин.

Чөнки Башкортстан мәктәпләрендә татар телен укыту сәгатьләре коточкыч дәрәҗәдә кысылганга күрә, бүген хәтта авылларда да татар телен фән югарылыгында белүче балалар бик санаулы гына. Аннары башкорт телендә укымау өчен мәктәпләрен урысныкына әйләндереп бетергән татар авыллары да йөзәрләгән инде. Милләт вәкилләре ул Бәләбәй педагогика техникумына Татарстаннан килүчеләр булмасмы, анда тулай торак та, спорт заллары, ашханә, хәтта стипендия дә бар, дип кызыктырып та куя. Ләкин Бәләбәй техникумы – Башкортстан Мәгариф һәм фән министрлыгына буйсына, ә аңа татар телендә белем бирүче техникум-гимназия һич кадерле түгел. Аңлашылып тора: әлеге педагогика техникумын саклап калу өчен Татарстан белән Башкортстан мәгариф министрлыкларының кулга-кул тотынып эшләве таләп ителә. Тик без ике министрлык арасында дуслык күпере пәйда буласына инана алмыйча гомер кичерәбез. Үзебездә барча педагогика институтлары ябылып юкка чыкты, Әстерхан, Пермь, Курган, Төмән өлкәләре генә түгел, Мәскәүдәге М.Җәлил исемендәге гимназия дә татар укытучыларына кытлык кичерә һәм без һаман – инде Бәләбәй техникумын да читтән карап торып юк итәбез...

Туймазы – сыңар гына башкорт авылы да булмаган, чип-чиста татар төбәге. Бәләбәй белән Ярмәкәй дә шулай. Гаҗәп түгел: татар халкы гомумсаны белән 200 меңгә җиткән төбәктә әдәбият һәм милли матбугат сөючеләр дә, үзләре шигырь һәм хикәя иҗат итүчеләр дә байтак. Бу яктан аеруча Октябрьский һәм Бәләбәй районнары үрнәк күрсәтә, Бәләбәйдә әдәби түгәрәк һәм берләшмәгә йөрүчеләр саны 280 нән арта. Әмма Уфада үзен корифей санаучылар татар шигъриятчеләрен игътибарга элми. Әйтик, узган елда Башкортстан китап нәшрияты 29 җыентыкны башкорт телендә нәшер иткән булса, татар китаплары 5 тән артмаган. Югыйсә, халык саны буенча татарлар күбрәк булса да, Башкортстан нәшрияты өчен алар йә икенче сортлы, йә сәләтсез милләт булып чыга.

(Дәвамы 12-13 нче битләрдә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ЯҢА СТАНДАРТЛАР ЯРАКЛЫМЫ?

Мәктәп-гимназияләрдә, башка уку йортларында яңа уку елы башланды. Аңа әзерлек чорында, гадәттәгечә, төрле конференцияләр, август киңәшмәләре һ.б. чаралар үткәрелде. Россия мәктәпләрендә быелгы төп үзенчәлек – 1 сентябрьдән башлап һәр яңа атна дәүләт гимнын башкару һәм дәүләт флагларын күтәрү белән башланып китте. Болардан тыш, мөһим сораулар турында сөйләшүләр һәм илнең дәүләт символларын өйрәнү буенча дәресләр дә уза. Ошбу яңалыкларның максатын укучыларда дәүләт символларына карата хөрмәт уяту, аларда патриотизм хисләре һәм үз иленә карата мәхәббәт тәрбияләү дип аңларга кирәк. Әлбәттә, андый тәртипне кертүчеләрнең ниятләрен дә аңларга була. Тик, үз Конституциясенә каршы килеп, төп халыкларының туган телләрен чикләгән һәм милли мәгарифләрен дә җимергән илдә (бигрәк тә, ул халыкларның балаларында) мондый ысул белән генә аңа карата хөрмәт вә мәхәббәт тәрбияләп буламы икән соң? Дөресен әйтик, илаһият кануннарына җавап бирми торган андый гамәлләрне рухи яктан сәламәт кешенең күңеле гомумән дә кабул итә алмыйдыр, чөнки, алар аның вөҗданенә каршы килә.

Үзгәрешләр исә Татарстан мәктәпләренә дә кагыла. Ул гына түгел, 1 сентябрьдән аларда уку планнарына, ата-аналар сайлавы нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт теле – татар теле» дигән фән кертелә. Мәгариф һәм фән министры И.Һадиуллин әйтүенчә, татар телен дәүләт теле һәм туган тел буларак укыту агымдагы елда федераль реестрга кертелгән үрнәк белем бирү һәм эш программалары буенча оештырылачак. Алга таба I һәм V сыйныф укучылары да яңартылган белем бирү стандартлары буенча укытылачак. Татарстанда быелдан театраль педагогика үсеше буенча федераль проект та гамәлгә куела һәм аның нигезендә, 2023 ел азагына гомуми белем бирү оешмаларында мәктәп театрлары оешачак икән. Болар хакында барлык мәктәпләргә дә РФ Мәгариф һәм фән министры раслаган ярдәм чаралар планы җибәрелгән. Аның максаты – бүгенге укучыда Ватан, кеше, гаилә, хезмәт кебек кыйммәтләр тәрбияләү. Әлбәттә, болар һәммәсе дә мөһим шәйдер. Тик әлеге кыйммәтләр системасында нигәдер туган төбәк, милләт, рухи тәрбия, әхлак кебек һәр кешегә кадерле кыйммәтләр күренми. Шуңадырмы, бу мәсьәләгә август киңәшмәсендә ясаган чыгышында Татарстан Президенты Р.Миңнеханов та игътибар иткән. Укытучыларның игътибарын ул яшьләрдә рухи-әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүгә юнәлткән, тәрбия эшендә ата-аналар потенциалын һәм челтәр ресурсы мөмкинлекләрен дә актив кулланырга, шулай ук туган телләрне өйрәнү өчен шартлар тудырырга чакырган.

Гомумән алганда, яңа уку елына республика әзерлекле килгән кебек. Һәрхәлдә, анда 11 яңа мәктәп ишекләрен ачуы, полилингваль мәктәпләр саны да икегә артуы (алар Әлмәттә һәм Түбән Камада төзелгән) һ.б. фактлар шул хакта сөйли. Шуның белән бергә, Россия мәгариф системасында милләтләрне борчый торган нәрсәләр дә күп. Алар иң элек анда Көнбатыш рухында әзерләнгән «РФ дәүләт милли сәясәте стратегиясе»нә туры китереп кертелгән үзгәрешләр белән бәйле. Милли күптөрлелекне бетерүгә исәп тотып үткәрелгән ул сәясәт соңгы 10 елда илдәге төп халыкларның милли мәгариф системалары тәмам җимерелүенә, ә туган телләрнең киләчәге куркыныч астына куелуына китерде. Әлбәттә, алар үзләре өчен иң кадерле кыйммәтләрнең мондый фаҗигале хәлгә куелуы белән бервакытта да килешмәячәк. Икенче яктан, туган телләрнең кыен хәле һәм илдәге төп халыкларның үз хокукларын парламентта яклау мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителүе аларны инде моңа каршы берләштерә торган уртак мотив та булып тора. Мәгълүм сәбәпләр аркасында Россиянең бүген тышкы сәясәттә үзенең дә кире кагылган илләр рәтенә куелуын исәпкә алсак, ике яңауның бергә туры килүе инде аның үз киләчәген дә куркыныч астына куя. Мондый шартларда аның өчен исән калуның бер генә ышанычлы юлы кала: илдә яшәү рәвешен илаһият кануннарына туры китереп үзгәртү. Мәгарифтә ул милли вә төбәк компонентларын укыту программаларына кире кайтаруны, милли мәктәпләрдә исә БДИне туган телдә тапшыруны аңлата. Болары – кичектергесез адымнар. Ә алга таба инде милли мәгариф системалары һәр халыкның туган телдә белем алуын ирекле һәм тулы канлы итәрлек дәрәҗәдә камилләштерелергә тиеш була.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәскәүлеләрне тарих кызыксындыра

Татарстан Мәскәүнең «Гостиный двор» күргәзмә комплексында төрле жанрдагы 300дән күбрәк китап тәкъдим итте. Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире урынбасары Венера Шәмсетдинова сүзләренчә, Мәскәү халыкара китап ярминкәсенә килүчеләр республиканың тарихы, гореф-гадәтләре һәм татар милли ризыклары белән кызыксына башлаган.

«Күпләрнең төрле тарихи дәвердәге җитәкчеләр, шулай ук татар ризыклары турында беләсе килә. Ике телле китапларга һәм сүзлекләргә дә ихтыяҗ зур», – дип сөйләде ул.

Аның сүзләренчә, Мәскәүдә июнь аенда узган ярминкәгә килүчеләрнең теләк-тәкъдимнәре хәзерге стендны ясаганда исәпкә алынган. Күпчелек кешенең күбрәк тарихи басмалар, балалар китаплары, тел өйрәнү әсбаплары күрәсе килгән. Стендтагы иң популяр китапларның берсе – татар, инглиз һәм рус телләрендә «Давайте говорить по-татарски» китабы.

Мәскәүдәге халыкара китап ярминкәсендә Россия төбәкләреннән, шулай ук Иран, Германия, Кыргызстан, Кытай, Казахстан һәм Белоруссиядән 300 дән артык оешма катнашты.

Театрлар дөньясында

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чаллыга эш сәфәре кысаларында «Мастеровые» рус драма театрын ачу тантанасында катнашты. 2 ел эчендә гомуми мәйданы 13 мең квадрат метрдан артык булган 4 катлы бина төзелде.

Камал театры бүген «Зәңгәр шәл» спектакле белән сезонын ача. 22 һәм 23 октябрьдә Кече залда Айдар Җаббаров япон драматургы Коки Митани әсәре буенча сәхнәләштергән «Көл» спектакленең премьерасы була.

5, 6 һәм 7 ноябрь көннәрендә театр Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» спектаклен тулы вариантта күрсәтергә вәгъдә итә. Май аенда аның ике пәрдәсе генә күрсәтелгән иде.

Тинчурин театрында Кәрим Тинчуринның ирекле тәрҗемәсе буенча «Хан кызы Турандык» спектакленең репетицияләре бара. Премьера драматургның тууына 135 ел тулуга багышлана. Режиссеры – Сәрдәр Таһировский (Венгрия). Спектакльнең премьерасы 15 сентябрьдә – К.Тинчуринның туган көнендә тәкъдим ителәчәк. Шул ук көнне театр үзенең яңа сезонын да ача.

«Әкият» курчак театры «ТУК-фест» театры фестивалендә катнашты.

Артистлар Удмуртия дәүләт милли театры сәхнәсендә Нәкый Исәнбәт әкиятенә нигезләнеп куелган «Мырау батыр» спектаклен күрсәтте. Аннары казанлылар Мәскәүгә юл тотты. «Истоки» I халыкара курчак театрлары фестивале кысаларында алар «Җырла, курай!.. Уйна, Шомбай!» спектаклен уйнады.

Әлмәт театры директоры Фәридә Исмәгыйлева Кырымда бара торган «Таврида» арт-кластеры мәйданында кече шәһәрдә милли театр үсеше, проблемалары турында чыгыш ясады.

Минзәлә театры, традицияләргә тугры калып, авыл тамашачыларын сөендерә. Бу атнада ул районның Әтрәкле авылында, күрше Тукай районының Кече Шилнә авылында Флорид Бүләков әсәре буенча куелган «Сөясеңме, сөймисеңме..» спектаклен тәкъдим итте.

«Театраль җомга» проекты кысаларында Түбән Кама театры артистлары Әлмәт шәһәре паркында Туфан Миңнуллинның «Кызлар кызык итәләр» спектаклен уйнады.

1 нче биттә – Бөгелмә районы Карабаш бистәсе фермеры Фәрит Нәбиуллинның татар атлары.
В. ИМАМОВ фотосы.

Иманлы мәктәпләр

Быел яңа уку елында Әлмәт шәһәрендәге «Нур» татар-мөселман мәктәбе бусагасын 70 бала атлап керде. Аларның ундүрте – беренче сыйныф укучысы. Бүгенге көндә мәктәптә 5 башлангыч сыйныф һәм 1 инглиз теле укытучысы, өстәмә белем бирүче 3 белгеч укыта.

Нәзарәтнең Алабуга шәһәрендә татар телендә тәрбия бирүче «Ихсан» мәктәбендә исә бу уку елында 25 укучы белем ала. Беренче сыйныфка 10 бала кабул ителде.

Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте Казанда намазга өйрәтү буенча «Ислам. Беренче дәресләр»гә тыңлаучылар туплау башланганлыгын хәбәр итте. Укытучылар тәһарәт, намаз, иман, хәләл һәм хәрам төшенчәләре буенча дәресләр үткәрәчәк. Әлеге мәктәп ислам дине кушканча яшәргә теләүче, әмма мәчет каршындагы курсларга йөрергә җае булмаган кешеләр өчен оештырыла. Укулар татар һәм рус телләрендә алып барыла. Дәресләргә 17 яше тулган һәркем йөри ала. Дәресләр шимбә көнне Галиев мәчетендә үткәреләчәк. Беренче дәрес 15 октябрьдә була.

Татар яшьләре ярдәм сорый

Казанда XXXII Татар яшьләре көннәре узды. Аның ябылу тантанасы алдыннан резолюция кабул ителде.

«Резолюция һәр ел саен Татар яшьләре көннәрендә кабул ителә. Без мондагы җитәкчеләр белән җыелып, аларның фикерләрен тыңладык. Үз тәкъдимнәребезне дә исәпкә алдык», – диде «Идел» яшьләр үзәге директоры Зөлфия Ибләминова.

Резолюциянең кайбер пунктлары.

– Милләтләр эшләре буенча федераль агентлыкка: РФ субъектларында татарларның милли-мәдәни берләшмәләре эшчәнлегенә финанс һәм матди ярдәм күрсәтү.

– Татарстан Президентына: Россия Федерациясе субъектларында, якын һәм ерак чит илләрендә татар яшьләре иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү.

– Мәдәни-гаммәви һәм спорт чараларын оештырганда (татар милли мәдәнияте һәм спорт өлкәсендә квалификацияле белгечләрне регионнарга, методик материаллар, костюмнар һәм милли атрибутика) ресурслар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә.

– Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгына: Грант нигезендә регионнарда татар яшьләре иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә системалы финанс ярдәме күрсәтергә.

– Татар яшьләре иҗтимагый берләшмәләренә: «Идел» яшьләр үзәгенә башкарылган эшләр турында квартал саен хисап бирергә.

– «Идел» яшьләр үзәге дәүләт учреждениесенә: РФ төбәкләренең татар оешмалары арасында тышкы һәм эчке элемтәләрне җайга салуга ярдәм итәргә.

Ябылу тантанасында татар яшьләре арасында лидер сайланды. 64 тавыш белән Самара өлкәсе «Туган тел» татар җәмгыятенең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе Фәрзәнә Мәхмүтова җиңде.

Заманча сәнгать мәктәбе

Әлмәттә реконструкциядән соң балалар сәнгать мәктәбе ачылды. Тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Президент Әлмәттә һәм республиканың башка районнарында социаль әһәмияткә ия объектлар төзүдә, ремонтлауда һәм реконструкцияләүдә ярдәм иткән өчен «Татнефть»кә һәм аның генераль директоры Наил Магановка рәхмәт әйтте.

Яңартылган мәктәптә 1000 бала укый ала. Монда декоратив-гамәли һәм сынлы сәнгать, скульптура, компьютер графикасы буенча мастер-класслар була. Моннан тыш, өлкәннәр өчен дә дәресләр оештырылачак.

Рөстәм Миңнеханов «Нур» яшьләр психологик ярдәм үзәгенең төзекләндерелгән бинасын да карады. Мондый объектлар Татарстанның 6 шәһәрендә бар. Монда психология юнәлеше буенча педагоглар эзерлиләр.

Эшлекле сәфәр кысаларында Президент Әлмәттәге «Адымнар» полилингваль комплексы белән дә танышты. Бу – Татарстандагы шундый алтынчы мәктәп. Белем йорты быелның 1 сентябреннән эшли башлады. Анда 800дән күбрәк бала укый.

Халык шагыйренә истәлек тактасы

Казанның Толстой урамында Роберт Миңнуллин яшәгән йортта шагыйрьгә мемориаль такта ачылды. Ачылу тантанасына Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Республика балалар китапханәсе вәкилләре, язучылар һәм шагыйрьнең иҗатын яратучылар җыелган иде.

М.Шәймиев чыгышында үзе язган шигъри юлларны укыды: «Әдәпле, зур йөрәкле, тыйнак, тирән фикерле – шундый шагыйрь Роберт безгә үрнәк түгелме? Татар, башкорт халкына син Ходайдан зур бүләк! Роберт иҗат чишмәсе эчеп туймас гаделлек».

Татарстан Дәүләт Советы спикеры Фәрит Мөхәммәтшин сүзен шәхесләребезне искә алу безнең бурычыбыз булуын әйтүдән башлады. «Аны соңгы юлга озаткач, исемен мәңгеләштерү өчен әле эшләнәсе эшләребез барлыгын тойдык. Язучылар берлеге, Мәдәният министрлыгы инициативасы Хөкүмәтебез тарафыннан якланып, чорыбызның бөек шәхесе яшәгән йортта мемориаль такта куелды», – диде ул.

«Карап торырга тыныч кына кеше принципиальлек кирәк булган мәсьәләләрдә трибунадан данлыклы чыгышлар ясады. Республиканың үсеш юллары турында башкачарак уйлаучыларга да Роберт Миңнуллин кирәкле сүзләрне таба белде. Һәркемнең йөрәгенә үтеп керде», – диде парламент рәисе.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла чыгышын Тукай сүзләре белән башлады. «Тукай әйткән бит: «Мин коеп куйган шагыйрь генә түгел, сәясәтче дә, дипломат та, җәмәгать эшлеклесе дә», дигән. Туры Тукайның дипломат булуын күз алдына китереп бетерә алмыйм – ул аны үзенчә күзаллаган, күрәсең. Роберт Миңнуллинга килгәндә, ул Тукай билгеләгән кысаларга сыйган кеше», – диде ул.

Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ үз чыгышында Р. Миңнуллинның шигырьләреннән өзекләр китерде. «Роберт үзенең шагыйрьлеге белән ике республика укучыларының йөрәген яулап алды. Беренче чиратта ул энкәйләрне үлемсезлек пьедесталына күтәрде», – диде Рәдиф Гаташ каләмдәше турында.

«Роберт халыкчан булды, гадел булды. Аны бик яраталар, чират торып фотога төшәләр иде. Халыкка якын булганга яратканнардыр аны», – диде шагыйрьнең хатыны Клара Миңнуллина. Ул Роберт Миңнуллинның исемен мәңгеләштерү эшләре өчен рәхмәтләрен әйтте. Республика балалар китапханәсенә Роберт Миңнуллин исеме бирелү вакыйгасын аерым әйтеп узды.

М.Шәймиев тантананың рәсми өлешеннән соң мемориаль тактага сокланып, аның югары дәрәҗәдә зәвыклы башкарылуын билгеләп үтте һәм автор – Тимофей Тюрингa рәхмәтләрен җиткерде.

Эчтәлекле күргәзмә

Ульяновск өлкәсе татар эшмәкәрләренең «Сембер» клубы тарих фәннәре кандидаты, танылган краевед Римма Вильдановaның күптәнге хыялын чынга ашырды. Алар күренекле шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү максаты белән Сембер татар сәүдәгәрләренә багышланган стенд-күргәзмә әзерләгәннәр.

Стенд-күргәзмәдә XIX-XX гасырларда Сембер төбәгендә яшәгән татар сәүдәгәрләре Акчуриннар, Абушаевлар, Алеевлар, Бахтеевлар һәм Тенишевләр нәселләренең данлыклы вәкилләре, аларның эш-гамәлләре, хәйриячелек эшчәнлеге турында бай эчтәлекле мәгълүматлар урын алган.

Ульяновскиның 17 нче китапханәсендә күргәзмәне татар җәмәгатьчелегенә тәкъдим итү кичәсе узды. Күргәзмәнең авторы, Сембер сәүдәгәрләренең тормыш юлын өйрәнүче Римма Вильданова мөһим вакыйгаларны, кызыклы фактларны искә алып үтте.

«Шөкер, төбәк тарихы белән кызыксынучылар саны елдан-ел арта бара. Нәсел агачларын - шәҗәрәләрен барлаучылар еш кына әби-бабалары яшәгән җирләргә аяк басалар, буыннар бәйләнешен, ерак тамырларын өйрәнәләр. Аларның һәрберсенә ярдәм итәргә тырышам, тарихи һәм истәлекле урыннарга экскурсиягә алып барам. Күпчелек сәүдәгәрләребез, татар зыялылары шәһәребезнең үзәк өлешендә гомер кичергәннәр, мәчет һәм мәдрәсәләр төзегәннәр, кибетләр тотканнар. Лосевая – Федерация урамында Акчуриннар, Алеевлар һәм Бахтеевлар көн күргән торак йортларның байтагы бүгенге көнгә кадәр сакланган. Соңгы елларда шуларның берничәсе өлкә мөселманнарының региональ диния нәзарәтенә кайтарып бирелде», – диде Римма Камил кызы.

Күргәзмәдә урын алган мәгълүматлардан күренгәнчә, сәүдәгәр Акчуриннар постау фабрикасы, агач эшкәртү комбинатлары тотканнар, бик күп мәчет һәм мәдрәсә салдырганнар. Мәсәлән, фабрикант Хәсән Акчурин укымышлы булып, тарих белән кызыксынган. Аның тимер акчалардан, кулдан язылган иске китаплардан тупланган китапханәсенә тиңнәр булмый. Акчуриннар гаиләсенең чит илдән кайтартылган пианиносы бүген Татар мәдәният үзәге музеенда олы ядкәр булып саклана.

1896 елда меценат Хәсән Алеев ярдәмендә (ул җир кишәрлеге бүлеп бирә) Мәләкәс шәһәрендә сафка бастырылган мәчет 1992 елда мөселманнарга яңадан кайтарылды.

Рузия ХӘЛИМОВА.

● Татарстан хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова әйтүенчә, республикада иң югары эш хакын сәнәгатьтә тәкъдим итәләр. Мәсәлән, министрлык базасында эш бирүче аена 143 мең сум вәгъдә иткән баш инженер вакансиясе бар икән. Скважиналарны химик эшкәртү операторы, монтажлаучы, эретеп ябыштыручыга эш бирүчеләр ай саен 100 әр мең сум, торба салучы машинистка аена 90 мең сум түләргә ышандыра.

● Казанда 190 миллион сумлык йорт сатыла. Аның мәйданы 1500 квадрат метр чамасы (дөресрәге, бу суммага ике йорт керә:төп йортның мәйданы 1468 кв.м, кунак йортыныкы 261 кв.м). Идел буе районының Кояшлы бистәсендә ябык, төзекләндерелгән һәм саклана торган территориядә урнашкан. Кишәрлекнең мәйданы – 42 сутый.

«Агыйдел» ансамбленә 10 яшь

В.Шәйхразиев ансамбль директоры Л.Ялалова белән.

Барча Татарстанга бердәнбер булып, Актаныш район үзәгендә эшләп килүче һәм үзенең яңадан-яңа тамашалары, бию һәм җырлары белән милләтебезне сөендереп яшәүче «Агыйдел» ансамбленең дәүләт статусы алуына 10 ел тулды һәм узган якшәмбедә Әлфия Авзалова исемендәге район Мәдәният сараенда зур тантана үтте.

Ансамбльнең тарихы, әлбәттә, тирәндәрәк. Яңа Актаныш әле бөтенләй юк, ә тау астында, Кара Иделгә терәлеп утырган авыл клубында район үзәгенең бер-ике дистәләп тиктормас, әмма сәнгатькә гашыйк егет-кызлары җыела да, һәр кич саен җырлап-биеп «мөгез» чыгара һәм туган якларының гына түгел, ә Сөн аръягындагы башкорт биюен, удмурт-мариныкын, ул вакытта таләп ителгәнчә, һичшиксез, рус биюен, аннары инде шуларга төрле җырлар да кушып шаккатыра башлый. 1966 елда нигезләнгән шушы һәвәскәр иҗат коллективына 3 елдан соң «халык ансамбле» исеме бирелә. Ә 2012 елда, район башлыгы Энгель Фәттахов республика җитәкчеләре алдында йөз суы түгеп йөри-йөри, «Агыйдел» коллективына «дәүләт ансамбле» статусын алдыруга ирешә. Коллективның бүген инде югары Актаныштa заманча яңартылган шәхси йорт-бинасы, дистәләгән штаты, җыр һәм бию өчен кием-костюм коллекциясе, иң мөһиме – дәрт һәм дәрманы бар.

Коллективны тәүге түгәрәк юбилее белән котларга Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе, премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев та килгән иде. «Агыйдел»ләләр сәфәр кылган, чыгыш ясаган төбәкләрне, шәһәрләрне искә алды ул. Вице-премьер санап күрсәткән дистәләгән калалар арасында Кырым республикасы, Төмән һәм Әстерхан, Башкортстан һәм Тыва, Бурятия, Саха шәһәрләре генә түгел, Мәскәү белән Петербург та, Урта Азиядәге Үзбәкстан, Кыргызстан, Казахстан, хәтта Төркия дәүләтләре дә бар.

«Агыйдел» ансамбле егет-кызларын, әлбәттә, районның элекке һәм бүгенге башлыклары Энгель Фәттахов һәм Ленар Зарипов та котлады. Коллектив директоры Лилия Ялалова, баш балетмейстер Лилия Фәтхуллина гына түгел, һәрбер җырчы һәм биюче диярлек Бөтендөнья татар конгрессы, Мәдәният министрлыгы, район хакимияте бүләкләренә лаек булды. Аннары Милли шура рәисе В.Шәйхразиев бөтенләй көтелмәгән башлангыч белән гаҗәпкә калдырды. Тантана сөекле җырчыбыз Әлфия апа Авзалова исемен йөртүче сарайда уза бит, ә ул башкарган җырларның күбесен татар халкы бүген дә оныта алмый. Васил әфәнде Әлфия апа аеруча яраткан җырларның беренче юлын башлап җибәрүе була, бөтен зал аңа кушыла. Шулай итеп, күмәк рәвештә дә өч истәлекле җыр күңел кылларын кузгатып та алды...

Л.Зарипов «Агыйдел» биючеләре белән.

«Агыйдел»не котларга килгән дуслары һәм хезмәттәшләре – санап бетергесез. Берсе дә ара ерак яки якшәмбе көн дип тормаган, шатлык уртаклашырга ашыккан. Республикабызның Татар җыр һәм бию ансамбле, керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» коллективы, күршеләрдән – Башкортстанның Фәйзи Гаскәров исемендәге дәүләт академия бию ансамбле, Удмуртия республикасының «Илексаз» дәүләт бию коллективы, Башкортстан филармониясенең Нефтекама филиалы вәкилләре, ызандаш Минзәлә һәм Мөслим районнарының мәдәният хезмәткәрләре һ.б.

Бәйрәм булгач, «Агыйдел» ансамбленең 70 яшьлек ветераны Робсон Мусин да, Казаннан кайткан якташларыбыз Азат Хөсәенов, Азат Нургалиев, Лилия Муллагалиева, Газинур Фарухшин да безне үз җырлары белән сөендерде. Ә «Агыйдел» сандугачы Рәзилә Галиева һичкем кабатлый алмас, бар республикада фәкать ул гына башкара алучы җыр осталыгы белән таң калдырды. Сәхнә тутырып һәм чиратларга тезелеп, республика районнары буенча меңгә якын «җырчы» һәм алар туплаган коллектив вакыт урлап, хәер җыеп йөри, ләкин Рәзилә шикелле шаккатыра алучылар Казанда да юк шул!..

Кич дәвамында «Агыйдел» башка ансамбльләр өчен чит-ят «Сөн буе татарлары биюе»н, «Әҗәкүл авылы» җырларын башкарып сокландырды. Ә иң мөһиме – алар үзләре үк «колакларыннан тартып» үстергән яшь алмаш – мәктәп укучыларының «Ак инеш» бию ансамбленә дә сәхнәдә урын бирде. Ул – «Созвездие-Йолдызлык» Бөтенроссия бәйгесендә Гран-при алган һәм Россия телеканаллары буенча да күрсәтелгән коллектив. Аны бүген «Агыйдел» ансамбленең баш балетмейстеры булып хезмәт куючы Лилия Фәтхуллина үзе нигезләгән. Менә шушы «Ак инеш» кебек яшь алмаш үсеп килү «Агыйдел»не республиканың барча бию ансамбльләре арасында үзенчәлекле итә. Башка ансамбльләр Алабуга, Чаллы, Казан сәнгать мәктәпләрен тәмамлап чыккан биюгә һәвәс егет һәм кызларны аулап йөри, ә «Агыйдел», әнә, үзенә алмашны «Ак инеш» кебек нәни дуслары арасыннан тәрбияләп ала...

«Агыйдел» ансамбле һаман юлда, туктаусыз хәрәкәттә. 10 сентябрь көнне ул Казахстанда узачак Сабан туе бәйрәмендә катнашачак.

В.ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Битлекләр турында битлекләрсез сөйләшү

Г.Тукай исемендәге Әтнә Татар дәүләт драма театры республикабызда беренчеләрдән булып бөек язучы Чыңгыз Айтматовның әсәре буенча яшь талантлы режиссер Илсур Казакбаев куйган «Ак пароход» спектакле белән 106 нчы иҗат фасылын башлап җибәрде һәм кыюлыгы, бөек язучының мирасына сакчыл карашы, җилләр кайсы яктан иссә дә, замана шаукымына бирелмичә, вакыт сынавын үткән затлы әдәбиятка тугры калуы белән чираттагы тапкыр сокландырды.

● Әтнә театры директоры Ленур Зәйнуллин һәм режиссёр Илсур Казакбаев.

Риваятьләр белән үрелеп барган вакыйганы сәхнә теле белән бәян итү ай-һай җиңел эш түгел. Әле аңа кадәр повестьны сәхнә теленә күчерәсе бар. Инсценировканы да үз өстенә алган режиссер Илсур Казакбаевка ничек сокланмыйсың?! Адәм баласының табигать белән арасы бозылу, халык традицияләренең цивилизация һөҗүме аркасында юкка чыгуы, яхшылык һәм явызлык көрәше турындагы күп яссылыклы, тирән мәгънәле әсәр буенча ничек оста итеп җыйнак спектакль иҗат иткән ул! Катнашучы геройлар күп булса да, бары Малайның (Рәзилә Шәрифуллина) һәм бабасы Момонның гына (Татарстанның атказанган артисты Марат Хәбибуллин) йөзләрен күрәбез. Алар гына чын һәм ихлас. Биш баласын һәм ирен югалткач, ни чарадан бичара юаш Момон белән кавышкан Әби (Дамир Сидеев), дөньядагы бөтен ачуын кысыр хатынныннан алучы Оразкол (Зиннур Һадиев), ана булу бәхетеннән мәхрүм Бикәй (Рәзинә Заһидуллина), автолавка йөртүче (Айдар Вәлиев), малайның этисе (Фаяз Хөсәенов), Сәетәхмәт (Ләйсән Каюмова) барысы да битлекләр кигән. Яши-яши кешенең эчке дөньясы йөзенә чыккан кебек, бу геройларның да тормыштан ризасыз булулары йөзләрендә ярылып ята. «Битлекле» алым малай авызыннан бәян ителгән һәм риваятьләр белән үрелеп барган бу спектакльгә килешеп тора. Ерактан караганда геройларның битлекләре кыпчак балбалларын хәтерләтә. Яхшылык һәм явызлык көрәше балбаллар гомере кебек озын тарихлы һәм ерак дәверләргә барып тоташа ич. Якыннан караганда исә, ямьсез битлекләрнең ирләр күлмәкләре яки костюмнарыннан төреп ясалганын күрергә мөмкин. Аларны күргәч, һәркем балачагын исенә төшерәдер. Кул астында нәрсә бар, шуннан, күңеленә нәрсә килсә, шуны әвәләү бала кулыннан гына килә. Чүпрәк курчаклар, агач атлар белән балачак һәркемнең күңеленә тирән уелып калган. Һәм чүпрәк битлекләр күргәч, шул самими дөньяга әйләнеп кайтканыңны сизми дә каласың. Балбал йөзләренә охшаш битлекләр тамашачыны иң баштан ук риваять геройлары Болан-ана (Зөһрә Мөхәммәтгалиева), яшь болан (Алинә Сидеева), боланнар (Фаяз Хөсәенов, Раил Сәләхиев, Рәсимә Асрутдинова) белән очрашуга һәм милли тамырлар юкка чыгу, буыннар арасында җепләр өзелү турындагы җитди әңгәмәгә әзерли.

Битлекле тамаша байтак вакыт дәвам итеп, йомшак Момон картның явыз Оразкол фәрманы буенча боланны үтерү сәхнәсеннән соң гына туктавында, бөтен геройларның, йөзләрен чүпрәк-чапрак белән бәйләп, бер-берсенә охшап калуында ниндидер бер хикмәт бар сыман. Малайның күңелендә бу усал, зәһәр кешеләргә карата моңа кадәр барыбер мәхәббәт яшәгән икән бит. Без моңа Малайның Болан-анадан Оразкол һәм Бикәй өчен бәбәй сорау сәхнәсендә дә шаһит булдык. Ятим тормышын бизәп, күңелен җылытып торган риваятьнең герое – болан үтерелгәч исә, Малай өчен бөтен геройлар бертигез төссез булып кала, күңелен аларга карата битарафлык биләп ала. Бигрәк тә самими карт Момонның үз йөзен югалтуы олы мәгънәгә ия. Момон Малай өчен гореф-гадәтләр өйрәтеп, нәсел-нәсәбе белән бәйләүче бердәнбер якын кеше иде бит. Бер яктан караганда, җинаять кылып, Момон малай өчен төссез, әһәмиятсез, «үле»гә әверелсә, бер үк вакытта Момонның бүтән геройлар белән бертигез төссез булып калуы гадәт-йолаларның, борынгы традицияләрнең җуелуын күрсәтә. Нәсел-нәсәбе җепләре өзелү боланны балта белән чабу сәхнәсендә аеруча оста күренә. Спектакль дәвамында сәхнәдә аркылы бәйләнгән һәм кирәксә – таулар булган, кирәксә – күлдәге дулкыннар булып тибрәлгән җепләр, балта белән суккан саен бер-бер артлы өзелә... Спектакльдә җәнлекләрнең артистлар тарафыннан оста гәүдәләндерелүе дә күңелгә уелып кала. Карт бия (Рәсимә Асрутдинова), мәсәлән – пластика ярдәмендә генә иҗат ителгән матур образларның берсе. Режиссер язучы Чыңгыз Айтматовның әсәрендәге табигатькә соклану хисен чагылдыра алган. Әледән-әле ишетелгән болан тавышлары, акчарлаклар авазы спектакльне тулы канлы итә.

Битлекләр кигән кешеләр һәм ак пароход турында хыял хакындагы битлекләрсез ихлас сөйләшү булды әлеге спектакль. Аны сәхнәләштерүгә рәссам Альберт Нестеров, композитор Магуля Мезинова, хореограф Ольга Даукаева саллы өлеш керткән. Әтнә театрының «Ак пароход»ы абруйлы театр фестивальләренең дә афишасын бизәрлек. «Ак пароход»ның ак юлларга чыгуы бәхәссез. Әлегә әтнәлеләр Г.Ибраһимов әсәре буенча куелган «Алмачуар» спектакле белән Грозныйга Бөтенроссия милли театрлар фестиваленә барырга җыена. Анда артистларыбыз унике театр труппасы белән иҗат көче сынашачак. Аннары Бишкәк шәһәрендә республикабызның йөзен күрсәтүче коллектив буларак, театральләштерелгән тамаша тәкъдим итәчәк. Театрның нигезендә торган шәхесләрнең берсе – Гомәр Мәрдәновның туган көне уңаеннан 18-19 ноябрьдә «Алты кызга бер кияү» спектаклен тәкъдим итмәкчеләр. Бу иҗат фасылында труппага Балтачтан Гөлия Гыйләҗева һәм Башкортстаннан Лиана Каюмова килеп кушылган. Сайтларында булдырылган «Әтнә театры радиосы» интернет аша бүгенге артистларның гына түгел, элгәрерәк иҗат иткәннәренең дә тавышларын яңгыратып, алар турында хәтерне сакларга ярдәм итә. Әтнә театрының бер дәүләт сыман оешып яши, иҗат итә белүе моңа кадәр дә сокландыра иде, бу юлы олыны-олы, кечене-кече итеп матур яшәүләре кабат җылы хисләр уятты. Моңа кадәр Әтнә театрының үз дипломы бар иде. Затлы бүләкне сезон барышында әйбәт иҗат иткән артист, режиссерларга бирәләр. Хәзер үзләренең алтын белән йөгертелгән көмеш күкрәк билгесен булдырганнар. Сезон ачылган көнне аны театрның сәнгать советы әгъзалары баш режиссер Р.Фазлыев, Татарстанның атказанган артисты М.Хәбибуллин, директор урынбасары, шагыйрә Г.Батталовага һ.б. тапшырдылар.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.
Рәмис НӘҖМИЕВ фотолары.

ОРЛЫГЫҢ НИ...

Әй татарым, орлыгың ни –
Тарымы син, бодаймы син?
Идел-Урал тарласына
Сипкән сине Ходаймы соң?

Алып килеп монда сине
Диңгезеңнән, тауларыңнан,
Иген сыман чәчкән сине,
Учлап-учлап тубалыңнан.

Киң колачтан сипкән сине
Идел-Урал арасына.
Белгән Халикъ хөр рухыңны,
Тар урынга сыймасыңны!

Әй татарым, орлыгың ни?
Бик тересең – тарыдыр син!
Корылыкка бирешмәгән
Тары сыман катыдырсың.

Әй татарым, арыштыр син –
Сокланалар егәреңә.
Бирешмәгән орлык көче
Меңәр еллык җилгәрүгә.

АВЫЛЫМ ХАТИРӘСЕ

Туган якка кайттым әле менә,
Сагындырган читтә гел йөреп.
Хатирәләр уяу, һәр тыкрыктан
Балачагым чыга йөгереп.

Эзләремне саклый Ык буйлары,
Бу сукмактан үрдәк-каз кудым.
Әрәмәдә бөрлегәннәр өздем,
Басмаларга басып кер юдым.

Өянкеләр һаман шул икән лә,
Кычыткannар һаман шук икән.
Күршеләргә сәлам бирим дисәм,
Кемгә дисәм, шулар юк икән!

Өй каршында мин утырткан сирень
Серен саклый башка берәүнең.
Якыннарым мине ятсыналар,
Киялеге читтә йөрүнең.

Кайтуымны беркем көтми кебек,
Урамнарны кат-кат урадым.
Балачагым йөрде арттан калмый,
Авыл хәтеренә уралып.

Асия ЮНЫСОВА

Минутларны саныйм димә
Комың беткән сәгатьтә.

«ТИТАНИК»

Син ниятләрең корасың,
Тәкъдир елмаеп куя.
Хыялыңның диңгезенә
Чыгарып куя кыя!

Иң бәхетле бер көнеңдә
Нидер була. Нигә, ник?
Хыялларың белән бергә
Төпкә китә «Титаник».

Ярый ла ул озатып калса,
Авазлар могҗизасы.
Бәлки, яшәү дәрестер ул,
Бу көнем, дип, соңгысы!

ЗАЯ ГОМЕР

Үкенечтән үкенеч ни үкенеч? –
Гомеркәйләр үткән заяга.
Дисбе төймәләре азая ла,
Әнә генә очы, азагы.

Кашкарыйлы көзге бакчаларга Төнге күкләр йолдыз койган чак...

Югалтмыйча орлык асылын
Меңәр елны кичкән бодай,
Тегермәннән исән чыккан,
Ак-пакь калган – ул син бугай!

Он иткәндә таш тәгәрмәч,
Әверелдең калачка син.
Кояшка тиң ипи тотып,
Ил каршына чыккан да син!

Әй татарым, орлыгың ни –
Тарымы син, бодаймы син?
Орлыгыңны яшәтергә
Балаларың калырмы соң?

КОЕ*

Әгәр белсәгез, эчә торган суларыгыздан хәбәр бирегез.
Коръән. «Хәл» сүрәсе, 68 нче аять

Болгар җирләренә барасым бар,
Сулар аласым бар коедан.
Мин үзгәрәм анда, алмашынам
Болгар җилгә битем куюдан.

Кылган юртып искән әремле җил
Сыйпап йөри Шәһри каберен.
Идел-Чулман кашы – асылташның
Ник җуелган тажлы кадере?

Чулпы җырын өзгән кылыч чыңы.
Кайсы көндә булган, кайчан бу?
Су хәтере тирән – шулай диләр –
Кое күзләрендә уйчан су.

Бабаларым эчкән судан хәбәр!
Ни беләсең, кое – меңъяшәр?
Мин болгарның татар оныгымын,
Уйчан күзгә карап эндәшәм.

Мең сорауга эзләп бер җавапны,
һаман киләм монда, юл чыгам.
Шыгыр-шыгыр чыгыр, җырлы чылбыр
Хәтерле су чыга юлчыга.

Кое суын эчкән сәхабәләр.
Иман иңгән җирдә тылсым бар.
Дым качырмый ун гасырлык кое,
әлгар илгә дога кайтсынга.

Уйлы күзгә өмет белән карап,
Күрдем анда дәвер күкрәвен.
Эчәр суы – мөлдерәмә кое!
Җирдән китмәс әле бу кавем.

* Шәһри Болгар музей-тыюлыгында Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан Болгар иленә ислам кануннарын өйрәтергә җибәрелгән сәхабәләрнең берсе – Габдрахман сәхабә коесы бар.

ТОЗ ТӘМЕ

Тозлы мәгарәдә яткан чакта,
Тоеп тәндә аның сихәтен,
Балачакка кайтып барладым мин
Әрнү сеңгән тозның хасиятен.

«Бакчы, кызым мунча кергән икән,
Тоз каптыңмы әле, балакай?» –
Шулай диеп, миңа тоз йоласын
Гел үтәтә иде бабакай.

«Тозны чәчә күрмә – олы гөнаһ.
Тоз чәчелсә – ызгыш азактан».
Тоз йоласы белән кисәтүдә
Саклау булган олы газаптан.

«Ипи-тозым сиңа – якты йөзем» –
Телгә килә сүзгә баш булып.
Ипи белән гел яшәә йөри –
Табыннарга килә аш булып.

Бездә гадәт – кунак каршылаулар
Ипи өсләренә тоз куеп.
Тозсыз сүздән күп чак тыелсак та,
Әйтер сүзне әйттек тоз коеп.

«Бер тоз гына аны төзәтер», – дип,
Яраларга яптык әрнетеп.
Терек суларына бәрабәр ул –
Канга сала табиб эретеп.

Тоз күп кирәк безгә. Тоз табабыз,
Тауны тишеп яки тау ватып.
Авыр хезмәт үзе тоз-таш булып
Буыннарга төшә кайвакыт.

Нужаларның хакын белгән бабам:
«Тоз кабып куй!» – дигән иде шул.
Ачы яшем, тозлы тирем өчен
Кирәгерен белгән икән шул.

КӨЗГЕ МАНЗАРА

Бәллүр тынлык кылын тибрәтеп,
Моң агыла көзгә багышлап.
Көзне каршы ала кояз миләш,
Ал тәлгәшләр белән алкышлап.

Мәтрүшкәләр өзеп, җиләк җыеп
Акланнарда истә йөргәннәр.
Җәй хәтерен инде кибән итеп
Болын куенына өйгәннәр.

Язын сайраганның көзге сые
Ындырларга кайтып тулган чак.
Кашкарыйлы көзге бакчаларга
Төнге күкләр йолдыз койган чак.

АВЫЛ ЗИРАТЫ

Авыл зиратында йөрдем
Уем белән икәүләп.
Авыл белән бергә яши
Зират дигән бер дәүләт.

Тып-тын дәүләт, бер дәгъвасыз:
«Сезгә калды дөньябыз!»
Мине сөйгән һәм мин сөйгән,
Якыннарым, монда сез!

Монда зират, монда тынлык,
һәр кабердә бер дөнья.
Якыннарым сагынганга
Килгән идем мин монда.

Монда гомрем шаһитлары,
Мондадыр әби-бабам.
Авылымда югалтканны
Мин монда килеп табам.

Тын зиратта моңлы хозур,
Кипкән үлән зыңлыгы.
Күбәләк тә какмый канат,
Бозмый зират тынлыгын.

Әни белән йөргән идек,
һәр чардуганны сыйпап.
Өч аршынлы каберләргә
Олы гомерләр сыйган.

Әни һаман дога кылды,
Тын җылытып учында.
Инде менә берьялгызым
Торам аяк очында.

КОМ СӘГАТЕ

Кем табышы – ком сәгате
Саный вакыт микъдарын.
Беркем белми сәгатеңдә
Тагын күпме ком барын.

Ком тузаны тар муенга
Ага баштa бик акрын.
Йөгерә-чаба ком минутлар,
Күренүгә ахыры.

Яши башлау мөмкин түгел,
Әйләндереп сәгатьне.

Үкенүдән хәзер ни файда ла,
Яшьлек үткән, йомгак сүтелгән.
Тәртәләргә тибәр генә чакта,
Тешне кысып, сабыр ителгән.

Татлылардан татлы бу ни татлы?
Бәгырь ярып, үксез наз ага.
Кала назлар, кала, кала ла!
Мөлдерәмә килеш казага.

КӨЗ ХАЛӘТЕ

Көз – шагыйрь ул! Айны кабызган да
Төсле шигырь язып утырган.
Шигырь язган битләр – яфракларны
Сукмакларга сибеп тутырган.

Көз хыялый! Төне буе тагын
Алтын тәңкә сибеп уйнаган.
Агач башларыннан очып узган,
Баланнарны кочып елаган.

Иртәгәсен инде уйланган ул –
Рәссам булып таңда уянган.
Мәрҗән күзле көзге миләшләрдә
Кинәт бәхет тоеп, ут янган.

Шагыйрь-рәссам белә кыл-каләмен
Кайсы төскә кайчан манасын.
Ул өлгерер язып кышка кадәр
Бу көзләрнең уйчан кыйссасын.

Яфракларга сеңгән җәй сагышын
Гомерләрнең талгын агышын,
Соңгы сәлам кебек алкышларны –
Күчмә кошның канат кагышын
Язын калдырыр ул китабына.
Яфракларның кыштырдавын басып
Нокта куяр елның хисабына.

РЕДАКЦИЯДӘН. Танылган шагыйрә һәм прозаик, Һ.Такташ, С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләр иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Асия Юнысовага шушы көннәрдә 75 яшь тулды. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

Татар исемнәренең төрлелеге – бәла!

Татар фамилияләренең төрлечә язылу күренеше еш очрый. Хәтта бертуганнарның фамилияләре төрлечә язылу очраклары да бик күп. Фамилияләр язылышындагы төрлелек – журналист өчен дә читен. Мәкалә язганда ребус чишкәндәй ачыклыйсың - кайсы дөрес була: Гимаева әллә Гыймаевамы, Абульханова яисә Әбелхановамы, Усмановмы әллә Госмановмы, Рахматуллин йә Рәхмәтуллинмы, Юсуповмы яисә Йосыповмы? ЗАГС киңәшмәләренең берсендә, Җәүдәт исеменең русча унике төрле язылышы бар, дип әйткәннәре истә. Зявдят та ул, Джаудат та, Джавдет та – ничек кенә язылмый!

Воркутада туган, Ульяновскида яшәгән җырчы Алсуның фамилиясен татар матбугаты «татарчалаштырып» «Әбелханова» дип яза. Википедиядә – Әбүлханова. Күптән түгел ул моңа дәгъва белдерде, фамилиясен «Абульханова» дип язуны сорады. Буа җырчысы Ринатны да «Рәхмәтуллин» дип язалар, ә ул үзенең «Рахматуллин» булуын әйтте. «Минем бабам Рахмат», ди җырчы. Кайсы дөрес? Кешенең фамилиясен «татарчалаштыру» ни дәрәҗәдә хаклы? Әгәр тулысынча татарчалаштырабыз икән, «Батров» фамилиясен нигә «Батыров» дип язмыйбыз? Һәм гомумән – кешенең исемен бозарга ярамаган кебек, фамилиясен «татарчалаштыру» да кирәкмәс бер гамәлме?

Төбәк тарихын өйрәнүче, тарих фәннәре кандидаты Нурулла Гариф татарларның исемнәре бозылып язылу проблемасы борынгы заманнардан килүе өчен ачына.

«Авыллар тарихын язганда, архивларда метрика кенәгәләрен Петр I чорыннан башлап өйрәнергә туры килә. Мәсәлән, Мөхәммәт исеме ничек кенә бозылып язылмаган: Мухмет та, Мехмет, Михмет та, башка төрләре дә бар, – ди Н.Гариф. – Сәбәбе бик гади. Бездә күпчелек исемнәр гарәп теленнән кергән, ә ул кириллицада язылганда автомат рәвештә бозыла. Кириллица гарәп авазларын тулысынча бирә алмый. Татар сүзләрен русчага күчереп карагыз. «Ә» хәрефе урынына «а», «е», «э» хәрефләре язабыз бит. Гарәп исемнәре латинга күчергәндә алай ук бозылмый».

Исемнәрнең күпләп бозылып язылуын күрсәткән кешегә ул теләсә кайсы татар зиратына кереп карарга тәкъдим итә.

«Күптән түгел Чистай зиратында йөрдем. Ул – тарихи кабер ташларына бик бай, музей кебек, ләкин соңгы берничә елда куелганнардан исем, фамилия, әтисенең исеме тулысынча дөрес язылган бер генә таш та юк. Кайбер кешеләр «таш язучылар татарча белми», дип уйлый, ләкин алар исемнәрнең язылышын заказ бирүчедән кул куйдырып ала. Алар 40-50 мең сум торган ташта хата җибәргән очракта үз хисабына төзәтәсе буласын яхшы аңлый. Гадәттә, ташны мәрхүмнең туганнары ясата. Кабер ташларындагы хаталар хәзерге буынның татарча укымаудан, татар телен начар белүеннән килә.

Бер йөз елдан соң, бозык исемнәр буенча кемнәрдер диссертация язачак әле. Бер-ике гасырдан соң яшәячәк буын: «2000 еллар чорында татарлар үз исемнәрен бозып язган, надан булган», – дигән фикергә киләчәк. Бу проблеманы чишү өчен, халыкның белемен арттырырга, балаларга татар телен укытырга кирәк. Кабер ташлары язучыларга исемнәр сүзлеге бирсәң дә комачауламас иде. Заказ бирүче, сүзлекләр карап, дөрес вариантын гына тәкъдим итәргә, ә ЗАГС хезмәткәрләре ике телне камил белергә тиеш», – ди ул.

Документта фамилиясенең хаталы язылуы Нурулла әфәнденең кечкенәдән теңкәсенә тигән. Шуңа күрә 2000 елларда ул аны алыштырган.

«Безнең бабай Гарәфетдин булган. Паспортка фамилияне Гарипов дип язганнар. Мәктәптә укыганда кайбер малайлар: «Синең бабаң гарип булганмы әллә?» – дип шаярта иде. Шуңа күрә бу фамилия теңкәгә нык тиде. Мөмкинлек туугач, балалар мәктәптә укыган елларда, без фамилияне «ов» кушымчасыннан башка гына – Гарифкә алыштырдык. Гариф «укымышлы» дигәнне аңлата. Аны эшләү бик җиңел булды. Башта ЗАГСка барып гариза яздым. Анда миңа яңа туу таныклыгы бирделәр. Шул документ белән паспортны алыштырдым. Яңа паспортка фамилияне үзгәртүем турында белешмә язылган. Шуңа күрә калган документларны алыштырып тору мәҗбүри түгел. Бу эшне яшь чакта эшләп куйсаң уңайлырак, чөнки балаларның бөтен документлары яңа фамилия белән китә. Хәзер балалар да, оныклар да Гариф булып йөри. Мин рәсми рәвештә фамилия алыштырган тагын ике кешене беләм. Шуларның берсе – тарих фәннәре кандидаты Рәшит Галләм».

Социаль челтәрләрдә «Дневник татарина» дип аталган юмористик сәхифәнең авторы һәм алып баручысы Рәмис Гыйльметдинов татарларда фамилия төрлелеге проблемасын юмор аша күрсәткән.

«Ни өчен биш туган биш фамилияле? Әгәр әтиеннең фамилиясе Сәлахов булса, калганнарыныкы Саяхов, Салихов дигән фамилияләргә әверелә. Югыйсә, бабай Сәлахов булгач, калганнар да Сәлахов булырга тиеш бит. Сезнең якларда да шулаймы?» – дип мөрәҗәгать итә ул видеоязма аша. Шунда ук ул үзенчә сәбәбен дә аңлата: «Барысына да ялкаулык һәм «паспорт өстәле» гаепле». Аннары автор паспортны тутыручы белән әңгәмәгә



пародия ясый. «Дневник татарина» сәхифәсенә язылучылар арасыннан егерменләп кеше, үзләрендә дә нәкъ шулай икәнен белдереп, комментарий язган. Сәгыйдә Нуриәхмәтова: «Без – җиде бертуган, җидебез җиде төрле язылганбыз», – дип таный.

Рәмис Гыйльметдиновтан ни өчен бу теманы күтәрергә булуы турында кызыксындык.

«Ни өчен бертуган ир-атлар төрле фамилия йөртә икән, дип күптән уйлана идем. Фамилия төрлелеге зиратта аеруча нык күренә. Бездә туганнар бер тирәдәрәк җирләнә. Башта бер нәселнең кабер ташларын карап чыктым. Бертуганнарның фамилияләре төрлечә язылган. Икенче нәселнең урынына барган идем, анда да шундый ук хәл. Өйгә кайтып әни белән фикерләштек тә, шушы видеоны төшерергә булдым», – дип аңлатты ул.

Татар исемнәренең язылышындагы төрлелекне киметү өчен, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ЗАГС заказы буенча, быел «Русча-татарча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге» төзеп тапшырган. Бу хакта институт директорының урынбасары Олег Хисамов хәбәр итте.

«Татар исемнәренең русча язылышында төрлелек зур. Аны татар халкының бәласе дип әйтергә дә була, – ди О.Хисамов. – Сәбәпләре тирәндә. Беренчедән, гарәп сүзләре кириллицага авыр күчерелә, ә татар исемнәренең күбесе гарәп теленнән кергән. Икенчедән, бер гасыр эчендә татар язма телен ике мәртәбә алыштырганнар. Өченчедән, документларга исем язучыларның күбесе татар телен белмәүче руслар булган. Алар ничек ишеткән – шулай язган.

Без бу төрлелекне киметергә, унификацияне сакларга тырышабыз. «Русча-татарча кеше исемнәре һәм фамилияләр сүзлеге»нең электрон варианты Фәннәр академиясе сайтының электрон сүзлекләр фондына урнаштырылыр.

Балага исемне ата-ана бирә. Әгәр ул аны үзенчә яздырырга теләге икән, аңа беркем дә каршы килә алмый, ләкин ЗАГС хезмәткәрләре дөрес вариантны тәкъдим итсен өчен, нигез буларак, сүзлек кирәк», – дип аңлатты галим.

Филология фәннәре докторы Рүзәл Йосыпов үз китапларын Юсупов фамилиясе белән чыгара, моның өчен аны тәнкыйтьлиләр. Ул үзе аңлата:

«Татарларда фамилияләр төрлелеге – күптәнге проблема. Китапларымда Юсупов фамилиясен язган өчен мине дә күп тәнкыйтьләделәр. Паспортта шулай язылгач, нишләтим? – ди ул. – Исемне төрлечә үзгәртеп язарга мөмкин, ә фамилия әти-бабайдан калгач, аның белән сак булу кирәк. Матбугатта кеше үз фамилиясен документтагыча күрсәтергә теләге икән – ул аның хокукы. Моңа журналистлар иҗади карасын, исемнәр бертөрле генә язылырга тиеш, дигән фикер йөртмәсен.

Матбугатта татар теленең бозылуы мине күбрәк борчый. Журналистларның берәрсе калька тәрҗемә белән бөтенләй ят сүз, сүзтезмә уйлап чыгара да, калганнары да шуны кабатлый. Орфографик хаталар турында әйтеп тә тормыйм. Хаталар туган телне начар белгәннән барлыкка килә».

КФУның Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе профессоры, татар теле белеме кафедрасы мөдире Гөлшат Галиуллина исемне милләтнең милли коды дип атый, исемнең дөрес язылышын һәм әйтелешен һәрдаим пропагандалап торырга кирәк, ди.

«Исем – ул сүз, аны саклауның анык рецепты юк. Моның өчен исемнәр, беренче чиратта, вакытлы матбугатта дөрес язылырга, радио-телевидениедә дөрес әйтелергә тиеш. Кайбер кеше матбугатта исем-фамилиясен паспорттагыча кулланылуны сорый. Андыйларның таләбен үтәмичә булмый, ләкин мөмкин кадәр күбрәк татарча вариантны кулланырга кирәк. Пропаганданың роле бик зур. Сүзлекләр куллану бик мөһим. Балага исем кушканда да сүзлекләрне карасак иде. Соңгы елларда балага исем кушу йолалсы торгызылып, популярлашып китте. Исем кушучы дин әһелләре ата-анага исемнең дөрес язылышын һәм әйтелешен аңлатсын иде. Татар халкы берничә графика алыштыруга карамастан, исемнәрнең милли яңгырашы бүгенге көнгә кадәр төгәл сакланган, аны югалтмаска кирәк», – ди галимә.

* * *

Татар исемнәре – буыннан-буынга күчеп килгән милли мирас. Туган телнең кулланышы кимеп барганда исем - кешенең милләтен билгеләүче бердәнбер тамга булып кала. Аны дөрес итеп куллану һәрберебездән тора. Шуңа күрә балаларга татар исемнәре кушыйк, аларны дөрес итеп языйк. Татарстаннылыларның туу һәм язылышу таныклыкларының ике телдә язылуы – зур бәхет. Башка төбәкләрдә яшәүче татарларның документа татар исемен дөрес итеп теркәп куюy мөмкинлеге дә юк. Безгә бу мөмкинлекнең кадерен белү кирәк.

Рифат КАЮМОВ.

Уфа каласында гомер итүче филология фәннәре докторы, Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Рәиф Әмиров белән әңгәмә.



Башкортстан татарлары – Казаннан аерылгысыз

– Рәиф әфәнде, былтыр узган җанисәп алдыннан төрле фаразлар әйтелде, Башкортстанда аның нәтиҗәләре нинди булыр, дип уйлыйсыз?

– Хәзер исәп-хисапка халык бик ышанмый, ничек язсалар да, без барыбер үзебез булып калабыз, дигән фикердә тора. Элеккеге исәп-хисап алулар вакытында саф «цекелдәп» торган мишәр авыллары башкорт авылы булып язылды, алардан сорап та тормадылар. 80 нче елларның икенче яртысындагы вәзгыять турында ул вакыттагы өлкә комитетының идеология буенча секретаре Таһир Ахунҗановның сөйләгәне бар иде. Мәскәүгә кемдер республиканың төп халкы кими, дип хәбәр иткән, имеш. Шуннан соң өлкә комитетына хисап тотыгыз, эш нидә, дигән фәрман төшергәннәр. «Без тоттык та берничә районда татар авылларын башкорт итеп яздык, шулай итеп татар белән башкортны тигезләдек».

Бу юлы да исәп алу формаль рәвештә барды, шуңа күрә халык «әй, теләсә ничек санагыз, без барыбер үзебез булып яшәячәкбез, статистика безнең миллилеккә зыян китерми» дигән фикердә.

– 2010 ел белән чагыштырганда, татарлар саны кимерме, артырмы?

– Исәп алу вакытында административ ресурс, көчләп яздыру дигән басым булмады. Ләкин күп кенә этлек контора-идарәләрдә эшләнде. Шуңа күрә башкорт халкы аз гына артыр, ә татарларның кимрәк булуы ихтимал.

–Халык «барыбер» дип әйтә дисез, чынлап та, барыберме?

– Өлкән, урта буын өчен ул барыбер. Чөнки XVI-XVIII гасырдан аермалы буларак, кеше кем булып язылса да, җирне аңа кирәгеннән артык бирмиләр бит. Элекке заманнарда җир өчен, татарлар йөз меңәрләп Казан губернасыннан күчеп килгән. Җир алу һәм күп кенә салымнарны түләмәү өчен, башкорт булып язылган.

Руда чыгарган атаклы сәнәгатьче Исмәгыйль Тасимовны гына алыйк. Алар Казан ягыннан Уфа губернасына күчкәч, җир өчен башкорт булып язылган. Берәүләр бүген дә Тасимовларның нәселен Татарстанда дип саный, икенчеләр Исмәгыйль Тасимовны «атаклы башкорт рудопромышленнигы» ди. Аңа Петербургта һәйкәл куйганда да, Башкортстан егетләре: «Безнең атаклы башкорт рудопромышленнигына Петербургта һәйкәл куелды», – дип шапырынды. Ә татар халкы мондый үзләштерүләргә төкереп тә бирми.

– Дөресме мондый караш?

– Аның нәтиҗәләре, үкенечкә, уку йортларында чагыла. Чынлап уйласаң, исәп алуда балалар түгел, ата-аналар катнаша бит. Ата-аналарны башка милләт кешесе дип язгач, мәгариф бүлеге кешеләренә дә дөрес мәгълүматны күрсәтмиләр. «Менә бу авылдагы ике урам үзләрен – татар, ә тегеләре – башкорт, дип язган, имеш. Шулай булгач, башкорт телендә укырга кирәк хәзер». Документ күрсәтеп сөйләшүче түрәләр юк, шулар үз ихтыярынча хәл итә.

– Нишләргә кирәк, дип саныйсыз?

– 90 нчы елларга – Бөтендөнья татар конгрессы оешкан чорларга әйләнеп кайтам. Ул бит бөтен дөньядагы иң актив эшләгән иҗтимагый, мәдәни җирле үзәкләргә таянып төзелде. Башкортстан да шактый актив иде. Мәктәпләр ачу булсынмы, башкасымы. Без йөри торгач, Башкортстанда хәтта татар телендә китаплар чыгару эше оештырылды. Ул бүлек – шул Башкортстан җирлеге өчен әзерләнгән уку әсбаплары белән милли әдәбиятлар бүлеге формасында әле дә эшләп килә. Ләкин башкорт, татар, башка милли мәктәпләрдә (мари мәктәпләренә чыгарма язсаргадыр) балалар саны кимегәннән-кими бара. Балалар саны кимү аркасында, мәктәпләр үзләреннән-үзләре ябыла. Минем туган авылымда шул 90 нчы елларга хәтле 9 классы мәктәп эшләп калган иде, хәзер мәктәптә бер унлап бала бар, алар күрше авылларга йөреп укый.

– Соңгы елларда төньяк-көнбатыш диалект дигән афәт тә туды бит әле, анысын ничек кабул иттегез?

– Русча әйткәндә, «от большого ума». Галим һәм галимәләргә эш кирәк. Аннан эш 80-90 нчы елларда гына түгел бит. Гомумән алсаң, «башкорт теле» дигән төшенчә юк бит ул, аны татар теле белән бергә кушарга кирәк. Башкорт галимнәре арасында «Нигә әле башкорт әдәби теленә нигез итеп Кувандык диалекты алынган, башка диалект алыныргa тиеш иде», дигән дәгъва да бар әле. Шуның чаткысы «төньяк-көнбатыш диалект» дигән мавыгуга китерде. Вакытсыз һәм кирәксез мавыгу бу. Татарстандагы тел галимнәренә дә рәнҗү, үпкәм бар. Алар Башкортстан татарларының тел-диалект мәсьәләләре белән шөгыльләнми. Менә, мисалга Танып диалекты. Мәрхүм Радик Нуретдинов «Танып диалекты» дигән монография чыгарды, диссертация әзерләде, әмма якларга өлгермичә китте. Ә «Танып диалекты» фәнни хуҗасыз калгач, ул хәзер «башкорт диалектына» әверелеп бара. Ә Таныпта – саф татарча сөйләшә торган халык. Танып диалекты дигән диалект бар инде ул, ләкин ул - татарча сөйләм бит. Ләкин рәсми фәндә танып диалекты хәзер башкорт диалекты дип йөри.

Башкортстандагы татар теле сөйләмнәрен фәнни нигездә раслап чыгучы юк. Менә Башкортстанда «мишәр дулкыны» бар. Патша хөкүмәте өчен мишәр – татар түгел, бөтенләй башка катлам булып кабул ителгән. Әйтик, рус казаклары бар бит – донские казаки, алар рус халкының аерым бер өлеше итеп каралган, алар – патша хөкүмәтенең ярдәмчеләре. Хөкүмәт аларны фетнәләрне бастыруда кулланган. Ә мишәрләрне мишәр-башкорт гаскәре составында чит ил походларына, Пруссия, Төркиягә каршы юнәлтелгән яу сәфәрләренә, Парижны яулап алу бәрелешләренә җиккәннәр. Польшадагы азатлык восстаниеләрен бастыру өчен 1772 елда ясалган поход турында әйтеп тә торасы юк. Аңлашыла булыр, Башкортстан мишәрләре һич бертөрле түгел, әмма алар бөтенләй өйрәнелмәгән.

– Хуҗасыз яткан малга ия тиз табыла. Башкортстанда тагын кайсы өлкәнең ныклы хуҗасы юк?

– Тартып алу өчен иң җиңеле – тел. Безнең тарих та буталып беткән бит. Мин заманында бер җанисәп алдыннан «Башкортстан татарлары» дигән китап әзерләп чыгардым. Райсоветларда, ЗАГСларда булган материалларны җыеп эшләгән идем. Кем үзен кайсы милләт вәкиле дип саный, шуны языгыз дип, хәтта учреждениеләргә дә анкеталар тараттык. Районнарны да кертеп, без аны алфавит тәртибендә эшләдек. Шул китап чыкканнан соң, «без татарбыз икән», диючеләр искиткеч күп булды.

– Сезне хуплаучылар да табылгандыр әле.

– Безнең бер профессор бар иде, мәрхүм райондашым Сибгатов. Ул әйтә иде: «Башкортстан биләмәсендә «башкорт» дигән сүз – милли төшенчә түгел, мал-мөлкәт төшенчәсе».

Совет чорында ул инде кадрлар сәясәтенә дә әверелгән. Бервакыт үз заманында зур исемнәр алган бер язучы белән сөйләшеп утырабыз. «Рәиф, һин башкортса җырлайһың, башкортса һөйләйһең, башкорт әдәбияты белән шөгыльләнәсең. Ә паспортыңны үзгәртсәң, әллә кайларга күтәрелеп китәсең», – ди. Кызу чак иде, сүктым да ектым моны. Торып утырды да: «Дөрес эшләдең», – ди. Мәрхүм инде хәзер.

– Башкортстанда «мишәрләр – аерым халык» дигән сәясәт яшәде, Балтач районында, әнә, «мишәр үзәге» дә ачылды, ә моның халыкны аеруда берәр нәтиҗәсе булырмы икән?

– Моннан алдагы җанисәп вакытында керәшеннәрне аерып карадылар бит инде. Аларны аергач, статистика, бәлки, башкорт файдасына бик нык үзгәргәндер. Бу кампанияне дә без «урындагы хакимияткә Мәскәүдән кушылган задание» дип кабул иттек. Әгәр дә мишәрләрнең этнографиясен, тарихын карап, музей сыман үзәк оештырып кына калсалар, алга таба көчәймәсә, әйбәт булыр иде. Мишәрнең тарихын, кем икәнен күрсәтеп ясаганда... Шул ук вакытта этнология институтының начар практикасы да бар бит. Шушыннан файдаланып, халыкны таркату, бүлгәләүгә омтылу сизелә.

– Татарстандагы татарлар Башкортстандагыларның нинди вәзгыятьне аңлап бетерми?

– Иң яманы: киләләр дә, концертларда чыгыш ясаганда, сәхнәдән: «Саумысыз, башкорт туганнар!» – диләр. Залда күпчелек татарлар утыра. Шул алып баручыларны өйрәтә-өйрәтә арып беттек инде. Нигә аерырга? Казаннан килгәннәргә залдагы татар тамашачысы туган түгелмени? Тел җәллисез яисә сәясәткә кирәргә теләмәүче булып кыланасыз икән, һичьюгы күршеләр, дип эндәшегез безгә.

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.

intertat.tatar.

Борынгы язма һәйкәл

Монголиянең Номгон үзәнендә Илтәриш каганга багышлап төзелгән борынгы тарихи һәйкәлләр табылган. Экспедицияне Халыкара Төрки академиясе Монголия фәннәр академиясенең тарих һәм археология институты белән берлектә оештырган.

Илтәриш каган (асыл исеме – Котлуг) – 682 елдан 693 елга кадәр идарә иткән Көнчыгыш төрки каганлыгы идарәчесе. 682-687 елларда көнчыгыш төркиләре Котлуг җитәкчелегендә Кытайга каршы сугышта җиңүгә ирешә. Соңрак алар «Икенче төрки каганлыгы» дигән дәүләтләрен яңадан төзи.

«Төрки каганлыгын яңадан торгызган Күлтәгин, Билге каганның әтисе Илтәриш каган хөрмәтенә багышлап ясалган комплекс һәм кабер ташлары табылды. Бу бик борынгы язма һәйкәл, анда беренче тапкыр «төрки» дигән сүз очрый», – дип сөйләгән Халыкара Төрки академиясе президенты Дархан Кыдырали Улан-Батордагы матбугат очрашуында.

Монголия фәннәр академиясенең тарих һәм археология институты директоры Гелегдорж Эрегзен Номгон үзәнендә фәнни археологик экспедиция нәтиҗәләре турында сөйләгән. «Номгон комплексы Монголиядә борынгы төрки дәверенең иң мөһим табышы булып тора. Аның гомуми мәйданы 49х41,5 метр тәшкил итә. Комплексның көнбатыш ягында таштан ясалган кеше сыннары, арыслан сыны һәм ике сарык сыны урнашкан», – дигән ул.

«Бу табыну урыны булган дип фараз кыла алабыз. Язма ядкәрнең ике кырыенда борынгы төрки рун язуы, ә өченче ягында согыд телендәге язу бар. Экспедициядә катнашкан галимнәр һәйкәл текстында «тәңре», «төрки», «котлуг», «түмен» кебек кайбер сүзләрне укый алды», – дип аңлаткан Гелегдорж Эрегзен.

Галим әйтүенчә, язма һәйкәлнең өске өлешендә ике бүре башы сурәтләнгән. «Алар аждаһага охшаган. Мондый каган атрибутлары Таспар каган, Билге, Күлтәгин һ. б. хөрмәтенә куелган һәйкәлләрнең өске өлешендә ясалганы билгеле», – дип билгеләп үткән ул.

Академия Номгон фәнни экспедициясе нәтиҗәләренә багышланган фәнни җыентык әзерләргә ниятли һәм аны төрки дәүләтләрдә таратачак. Монголиядә төрки дәвер һәйкәлләрен казу эшләре алга таба да дәвам итәчәк.

Зилә МӨБАРӘКШИНА.

ЯЗМЫШЫҢА ЫШАН

Газиз КАШАПОВ

Теге көнне, нindидер аңлашылмас һәм күзгә күренмәс бер көч Гаярның үзсүзле башын һич көтмәгәндә Гөлфирәнең күкрәгенә салырга мәҗбүр итте. Йөрәгендә ничәмә-ничә еллар буена сүнмичә-сүрелмичә йөргән яшьлек мәхәббәтенең исән булуын һәм төтенсез дары кебек кабынып китәргә әзер икәнлеген аңлады ул. Төзелештәге эшләрнең барыр-бармас, җайланыр-җайланмас булуына карамастан, искиткеч зур өмет һәм хыяллар белән яши башлады Гаяр. Мондагы күңелсезлекләр, йөрәккә никадәр генә якын булмасын, вакытлыча гына туган күңелсезлекләр иде. Алар күпмедер вакыттан соң, яңа төзелешнең олы тәгәрмәче бар куәткә әйләнә башлагач та югалачак, ә күңелнең иң ерак түрендә озак еллар буена эшерәнеп яткан беренче мәхәббәтнең ирек татымаган тойгылары Гаяр Сәфәровны тормышның тәмен белеп яшәргә мәҗбүр итәчәк иде.

Теге көнне, Гөлфирә белән сүзсез аңлашудан соң, Гаяр үзенең больницадан ничек чыгып киткәнен томан аша гына хәтерләде. Ул көнне Гаяр әллә никадәр эш эшләде, моңарчы хәл ителмичә килгән нәрсәләрне хәл итте, табасын тапты, аласын алды. Кичкырын, Чаллыдагы эшләрен бетергәч, үзенең квартирасы барлыгын, анда сөекле кызы Карлыгачның көтеп утырганын да онытa язды хәтта. Ярты сәгать эчендә ул Карлыгачын җыйды да, күршеләренә квартира ачкычын биреп, тегесен-монысын караштыра торырга кушып, Көмеш Аланга ашкынды. Аннары, Ширәмәт тавыннан төшкәндә, больница ягына күзен тутырып-тутырып карады. Бер мәлне: «Әллә тагын кереп чыгаргамы?» – дип уйлап та алды. Ләкин вакытның инде соң, больницадагыларның бу сәгатьтә йоклап ятуларын чамалады, җилкәсенә сыенып мышный-мышный йоклаучы кызының чәчләренә битен куеп, кысыбрак кочаклады, тагын уйларына бирелде.

Өч көн һәм өч төн күрмәде ул аны. Мәктәп бинасын – Көмеш Аландагы беренче өч катлы бинаны –монтажлауның иң кызган чагы, кирәкле детальләрне йә бөтенләй китермичә торулары йә Чаллыярдагы йортларга ярамыйча, артып калганнарын китереп аударулары мөмкин иде, шуңа күрә, соңгы стенаны урынына куйганчы, Гаяр монтажчылар яныннан китмәде, бригадир чагындагы кебек, үз куллары белән байтак эшне эшләде.

Казаннан килгән кунаклар ярыйсы гына талымлы кешеләр булып чыкты. Айбулатов аларга үзе җитәкләгән комбинатка караган оешмаларны күрсәтте, объектларга алып барды. Башкаланың башкарма советы председателе урынбасары, төзелеш эшләре белән турыдан-туры шөгыльләнүче Аксурин сорау биреп, комбинатның эчке серләрен, теге яки бу эшне, мәсьәләне нинди юллар белән әйләндереп чыгарулары турында бигрәк тә төпченеп, кат-кат сорашты. Яңа шәһәрнең, шушы араларда кешеләр кертергә дип әзерләнгән, кияү егете сыман көяз, аның кәләшедәй саф һәм җыйнак комплексларын карап, торак йортларга кереп, аларның эчке әзерлеген тикшереп чыккач, әлеге Аксурин:

– Әйтегез әле, иптәш Айбулатов, гадәттә, тапшырыла торган йортларда бик күп җитешсезлекләр табыла. Йә тегесе житми, йә монысы эшләнмәгән була. Ә сез хәтта су краннарын, газ плитәләрен дә көйләп куйгансыз. Бу бөтен йортларда да шулаймы? Әллә, мин әйтәм, Чаллыярны күрергә килүче күп булгач, начар нәрсә күрсәтәсегез килмәгәнгә, боларын гына шулай җыйнакладыгызмы? – дип төрттереп куйды.

Айбулатов кунакның мондый тыйнаксызлыгын ишетмәгәнгә тырышып караган иде, тегесе үзсүзләнеп соравын тагы кабатлагач, түзмәде, күзләрен кыса төшеп ярып салды:

– Без бит, иптәш Аксурин, сезне ирексезләп чакырмадык, үзегез күрергә килдегез. Без күрсәткәннәргә ышанасы булмагач, нигә килдегез? Минем, бәхеткә каршы, сез шикләнгән нәрсәләрне берәмтекләп күрсәтеп йөрергә, шуның белән үзебезнең төзүчеләр хезмәтенең зурлыгына, аларның тырышлыгына тап ташларга вакытым кысанрак. Ышанмыйсыз икән, менә бу комплекста әзерләнгән меңнәрчә квадрат метр торак мәйданны тәшкил иткән йортларның һәр подъездын үзегез әйләнеп чыгыгыз, ярыймы? – дип, ярыйсы гына тупас җавап кайтарды.

«Татарстан»да кунакларга төшке ашны ашатып, ял итәргә калдыргач та, Айбулатов идарәдәге эш бүлмәсенә юнәлде. Үзәк почта һәм телеграф почмагына борылып, Җәлил проспектына чыкканда, алар артыннан килгән «Волга» калтыравык тавыш белән кычкыртып куйды. Айбулатов сулгарак каерылып караса – Мирас Гайнанович икән. Ул, машинасының ачык тәрәзәсеннән уң кулын сузып, «минем арттан барыгыз» дип ишарә ясады һәм, туктап-нитеп тормыйча, борылышка кереде, шәһәр комитетының ишек каршына ук барып туктады.

Көннең эсселеге аз гына да сүрелмәгән иде әле. Мирас Гайнанович битен-күзен кульяулыгы белән сөртә-сөртә, Айбулатовны көтеп алып, бүлмәсенә ияртеп кереп китте.

Кабул итү бүлмәсе аша узганда, секретарена кушарга да онытмады: «Чәй кертегез!» Байтак кына тегесен-монысын эшләде, телефоннан сөйләшеп алырга өлгерде. Ниһаять, секретарь кыз чәй әзерләп кертте.

– Әйдәле, Айбулатов... Сусауны басып алыйк әле. Бәлки, кем белә, соң... гы тапкырдыр. – Ул суза төшебрәк әйтеп куйды һәм, әйткән сүзенә үзе дә игътибар биреп җиткермәгән кеше сыман, тамак кыргалады.

Айбулатов мондый хәлнең тиктомалга түгеллеген нindидер җитди сөйләшү булырга тиешлеген чамалый иде чамалавын, әмма тәгаен белми һәм шуңа күрә ни уйларга да аптырап утыра иде.

Ниһаять, ул телгә килде.

– Бүген, Мирас Гайнанович, иртәдән бирле нindидер киная белән сөйләшәсез әле. Нишләптер минем зирәклек җитеп бетми, ни әйтергә теләвегезне – орышыргамы, мактаргамы дигәндәй, аңлап бетермим бит әле.

– Турысын әйтергә дә мөмкин, Фазыл Артышевич, ләкин бит сез үзегез шәһәр комитетының беренче секретаре белән турысын әйтеп сөйләшергә бик үк ашкынмыйсыз...

Айбулатовка бу сүзләр сәер тоелды.

– Нигә алай дисез, Мирас Гайнанович. Әгәр дә кирәге чыга икән, үзегез беләсез, сезгә килмичә калганыбыз юк бит әле.

– Шулаен шулай... Тик «кирәге чыккан-да» бит ул. Әгәр кирәге чыкмаса... Мин, билгеле, Айбулатов, турысын да әйтә алам: Казан кунакларының тел төбеннән аңлавымча, беркөнне өлкә комитетында Казанда торак төзү мәсьәләләренә багышланган киңәшмәдән соң сезне беренче секретарь аерым алып калып сөйләшкән...

Аңлашылды, барысы да аңлашылды Айбулатовка.

– Күптәнге мәсьәлә бит инде бу, Мирас Гайнанович, – диде ул җиңел сулап. – Миңа калса, сез минем фикерне беләсездер дип уйлаган идем.

– Белүен беләм, иптәш Айбулатов, әмма Чаллыярдагы йортлар комбинаты җитәкчесе булуга караганда, башкаладагы шундый берничә комбинатны берләштергән Баш идарәне җитәкләү сезнең өчен хәлдән килми торган эш түгел, минемчә...

Чәйләр суынып өлгергән иде инде, Мирас Гайнанович яңартып кертүләрен үтенде. Ул да түгел телефон хәбәр салды, өлкә комитетының беренче секретаре шылтырата икән. Сүзнең ахырында гына ул Казаннан килгән кунаклар турында сорашты бугай.

– Айбулатов аларга барлык серләрен сөйләп бетерде инде, бездән битәррәк эшли башламагайлары, – дип каршысындагы әңгәмәдәшенә күз кысты Мирас Гайнанович.

Айбулатов сизде: Борнашевның кармак салып каравы иде бу. Өлкә комитетының беренче секретаре беркөнге сөйләшүдә кузгатылган мәсьәләне Борнашевка җиткерде булса кирәк, чөнки Мирас Гайнанович аңа «Шулай, әйе, үзе нәрсә әйтер бит әле», – дип җавап бирде. Аннары гына:

– Мин бу эшне, иптәш секретарь, бик үк уңышлы сайланган, уйланылган дип әйтмәс идем. Чөнки, үзегез беләсез, Айбулатов Чаллыярны төзүдә беренче көннән катнашкан кеше. Хәзер әнә, «үз шәһәремне салам дип», Көмеш Алан белән җенләнә. Мондагы төзелешнең зурлыгын беләсез. Хөкүмәтнең Чаллыярны үстерүгә өстәмә средстволар билгеләве җаваплылыкны арттырды гына. Аннары бит әле безнең үзебездә дә андагы баш идарәдән зуррак булган берләшмә бар... Озакламый анда да үзебездә үскән кеше кирәк булмагае... Ярый... Ярый, сөйләшермен. Алай да була. Үзегезме? Биредә ул, минем янда утыра... Әйтермен.

Чәй яңартып китерделәр. Борнашев өлкә комитет секретаре белән сөйләшкән тәэсирдән арынып бетә алмый иде әле, авызын пешерә-пешерә бер-ике йотым чәй капты да Айбулатовка таба борылып утырды:

– Менә шулай бит без, Фазыл кордаш. Үзебезне үстергән, тауларга күтәргән якларга рәхмәтне шулайрак әйтәбез кайчакта. Шуның өчен дә безнең җиде-сигез миллионлы халыкның иң талантлы кешеләре – белгечләре, оештыру сәләтлеләре, гомумән, талант ияләре бөтен илгә таралган. Элек-электән шулай булган бу. Әйтерсең безнең республикада аларга колач юк. Мин сездән дә моны көтмәгән идем. Ничек инде шулай җиңел генә Чаллыярны, үз кулларыгыз белән торгызышкан, күпме өлешегез кергән, йокысыз төннәр, күпме шатлыклар кичергән Чаллыярны, ахыр чиге үзегезнең яшьлегез үткән җирне ташлап китәргә мөмкин? Аңламыйм...

Айбулатов, шәһәр комитеты секретаре сөйләгән арада, берничә тапкыр бүлдерергә, нәрсәдер әйтергә теләп караса да, тукталып-тукталып калырга мәҗбүр булды. Ниһаять:

– Мин, Мирас Гайнанович, әле Казанда чакта ук тәкъдим ителгән урыннан баш тарттым. Мин анда күчәргә ризалык биреп кайтмадым бит. Мине Чаллыярда гади инженер итеп прораб итеп булса да калдырыгыз, дидем. Баш идарә җитәкчесе булу мине кызыктырмый...

(Дәвамы киләсе санда).

«Татар аргамагы» үзенә чакыра

Казанның Горький һәм Шаляпин музеенда «Татар аргамагы» дип аталган Бөтенроссия рәсем сәнгате күргәзмәсе эшли башлады. Ул рәссамнар, артистлар, язучылар, сәнгать белгечләре, журналистлар һ.б. катнашында тантаналы төстә ачылды.

Бу көнне Горький һәм Шаляпин музеенда чын татар халык бәйрәме оештырылды. Бер-берсенең иҗнәреннән алган ир-егетләрнең күргәзмәләр залын гармун тартып, авыл урамындагыча җырлап үтүләре дә, музейны шаулатып татарча биюләре дә җанга якын иде. Шул арада атлар кешнәве дә ишетелгәндәй була. Диварларда исә – Комсомольск-на-Амуре, Кемерово, Череповец, Мәскәү, Санкт-Петербург, Самара шәһәрләреннән, Татарстан, Чуашстан, Башкортстан республикаларыннан, шулай ук Кыргызстан һәм Беларусь мәмләкәтләреннән 45 рәссамның атлар төшерелгән йөздән артык картиналары. Аларның һәркайсында атларга булган күңел җылысы, туган җирен ярату хисләре чагыла. Күргәзмәдә Җ.Базарбаев, В.Филиппов, П.Илюшкина, А.Саттаров, И.Фәтхуллин, Е.Баймяшкина, Р.Хәнәфиев, Р.Мөхәмәтдинов һ.б. танылган рәссамнарның эшләрен күрергә мөмкин. Алар эчтәлеге белән уйландыра. Горький һәм Шаляпин музее директоры Марианна Гаврилова да, бу залда күп күргәзмәләр үтүен әйтеп, «Монысы үзенә аерым, татарча һәм шул ук вакытта креатив», - дип аның үзенчәлеген билгеләде. Татарстан рәссамнар берлеге рәисе Альберт Шиабиев исә «Татар аргамагы» күргәзмәсе төрле кылкаләм осталарының иҗатын күрсәтеп алу мөмкинлеге дә икәнлеген искәртте.

Барысы да Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗевның Лениногорск районы Югары Каран авылы фермеры – «Алмакай» атлар утары җитәкчесе Фәрит Нәбиуллинның маллары утлый торган утарын күрүдән башлана. Анда 500 ләп ат кешнәп йөри. Көтүнең иге-чиге күренми. Бу матурлыкка рәссам сокланып туя алмый, ул атларны рәсем сәнгатендә теркәп калдыру теләге белән яна башлый. Рәссам ниятен Фәрит Нәбиуллинга да җиткерә. Шулай итеп берничә көн атларны сурәтләп йөри. Әмма бер пумала белән генә булмый. Шуннан соң башка рәссамнарга да, атлар утарын килеп карагыз, күргәзмә ясарбыз, дип хәбәр бирәләр. Бу чакыруны Россия күләмендә иҗат итүче рәссамнар кабул итә. Беренче күргәзмә Лениногорскиның үзендә оештырыла һәм уңышлы үтә, аннары экспозиция Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы, Чаллы, Түбән Кама сәнгать сөючеләренә тәкъдим ителеп, Казанга кайта. «Бүген Горький музеенда – атлар бәйрәме, хыялым тормышка ашуына шатланам. Лениногорски җирендә 20 ел яшәп, шуннан алган көч, Фәрит Нәбиуллинның рәхмәте, аның кодрәте белән, фермерның алтын төсендәге татар атларын Казанга алып килдем. Бүген монда ат җене кагылганнар, ир-атлар бәйрәме», – ди М.Минһаҗев.

Хәтерләсәк, татар һәрвакыт атлы булган, аның утарында 2-3 аты кешнәгән. Әмма 1930 елларда халыктан күмәк хуҗалыкларга атларны тартып алдылар, татарны атсыз иттеләр. Әдәбият галиме-текстолог, нәкышчы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Нәҗип Нәккаш соңгы 50-70 елда халкыбыз өчен атларны сагынып искә алырга гына калганын искәртте. Аның әнисе ягыннан бабасының 1924 елда атлары булган әле. Әмма аларны күмәк хуҗалыкка тапшырырга мәҗбүр иткәннәр, ул шулай Себергә китүдән котылып калган. Ул малкайларын шулкадәр сагынып сөйли торган була. «Колхоздан ат алу бик уңайсыз иде. Ә атсыз терлек азыгы да әзерли алмыйсың. Халык уфалла арбасына үзе җигелде. Безнең Үсәли авылында хастаханә, урта мәктәп бар иде. Аларда ат булуы кирәк. Урманчы да атта йөрергә тиеш. Әти бригадир булып эшләде. Аңа Такси кушаматлы алаша билгеләделәр. Мин аны болынга алып төшеп, тышаулап җибәрә идем. Ә гади колхозчыга ат бирмәделәр. Атлы булса, ул үзенә тормышын алып бара, ризыкны таба, азат була, болай күмәк хуҗалыкка бәйле, таякка эшләргә мәҗбүр ителде. Атлар озак еллар дәвамында татар халкының хыялында гына яшәде», – дип искә алды ул. Атлар тора-бара күмәк хуҗалыклардан да юкка чыкты, бүген бер аты да булмаган авыллар арткannan-арта бара.

Әйткәнебезчә, татар гомер-бакый атлы халык булган. «Татар аты» токымлы аргамаклар әүвәлге заманнарда хуҗалыкта һәм хәрби эштә кулланылган, аннары алар юкка чыккан диярлек.

«Татар аты» дигән аерым токым барлыгын тарихчы Рафаил Бәдертдинов язып чыга. Аны фермер Ф.Нәбиуллин күтәреп ала. Нәкъ менә ул татар атларының борынгы токымын торгызуга һәм үрчетүгә нигез салучы булды. Фермер беренче татар атларын хуҗалыгына Башкортстанның Туймазы районыннан, Чиләбе якларыннан алып кайткан. Бу токым феноменаль чыдамлыкка ия, алар 7-8 сәгать буена өзлексез хәрәкәттә булып, 100-120 чакрым араны үтәргә сәләтле. Шул ук вакытта татар атлары югары үрчемле, эссегә һәм салкынга түзем. Россия иппология фәне дә татар атларының бу сыйфатларын раслады. Бүген инде Татар атлары халкыбызның горурлыгы һәм байлыгы булып тора. Тарихчы Илдар Сафинның күргәзмәне ачу тантанасында Ф.Нәбиуллинга, М.Миңһаҗевка, Р.Бәдертдиновка татар атларының логотибын тапшыруы олуг мәгънәгә ия иде.

Гомумән алганда, белгечләр дөньяда 400 дән артык ат токымы булуын искәртә, 2019 елның февраль аенда аларга татар аты токымы – аргамак өстәлде: аны РФ Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының дәүләт комиссиясе теркәгән. Бүгенге көндә токымлы татар атлары Зәй, Әлки, Азнакай, Балтач, Теләче, Саба һәм башка районнарда тарала башлаган.

Ф.Нәбиуллин искәрткәнчә, атка атланган кешенең уе, да фикере дә, тормышы да икенче төрле. Фермер да бүген татар атларын кайтарырга теләп башлаган эшне төгәлләп чыга алуларына куана. «Без атларга бәйле милли уеннарны яңарттык. Бу эшләр алга таба да дәвам итәчәк. Авылдан шәһәрләргә киткән милләттәшләребез телебезне дә, гореф-гадәтләребезне дә югалтып бара. Рәссамнарыбыз иҗаты булган бу күргәзмә аларны уятсын иде. Атыбыз авылны сакларга, халкыбызны күтәрергә кайтты», – диде Ф.Нәбиуллин.

Күргәзмәне күрергә балалары белән килүче әти-әниләр дә күп. Рәссамнар балаларда да атларга мәхәббәт уятуны максат итә. «Алмакай» атлар утары һәм Татарстан рәссамнар берлеге оештырган күргәзмәне 25 сентябрьгә кадәр музей билетлары һәм Пушкин картасы буенча карарга мөмкин.

Күргәзмәне ачу тантанасын Зөлфирә Сөнгатуллина алып барды. Бәйрәм Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев, музыкант, композитор, педагог Рафинат Сәләхов, Татарстанның атказанган артистлары Шамил Галиев, Фәрит Мирзануров чыгышлары белән үрелеп барды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

●Туймазыда Фәнир Галимов төзеп куйган татар иҗтимагый үзәге.

●Иҗтимагый үзәктә истәлеккә төшкән фото.

ТУЙМАЗЫ –

●1870 елда төзелгән җил тегермәне.



●«Бабай утары»нда 19-20нче гасыр чигендә төзелгән татар йорты.

●Татар йортының эчке күренеше.

(Дәвамы. Башы 2 нче биттә).

Шул ук вакытта Татарстан китап нәшрияты да Башкортстанда яшәгән, өстәвенә әле бер республиканың да иҗат союзына кабул ителмәгән «башлап язучыларга» үзенең тематик планнарында бөтенләй урын бирми. Талантлы булса да, чикнең аръягында туган татар үзенең Башкортстанда яшәгәне өчен гаепле килеп чыга. Менә шушы тышау-түгәрәкне өзеп чыга алмаганга күрә, Бәләбәй һәм Октябрьскийда яшәүче «яшь» әдипләр тәүге китапларын үз акчаларына чыгарырга мәҗбүр. Алар арасында 12-14 китап чыгарып та һаман «яшь» һәм «союзсыз» булып саналган иҗат ияләре дистәләгән. Алар күңелләре һәм иҗатлары белән Казанга тартыла, тик безнең мәркәздәгеләр кочак ачып тормый: «Сезнең Башкортстан язучылар берлегендә татар әдипләренең аерым бүлеге бар бит, шигырь һәм хикәяләрегезне тикшертергә шунда барыгыз, китапларыгызны чыгару мәсьәләсен дә шулар хәл итәр». Мондый «ясалма үгилекне» туктатмыйча булмый, чөнки алар безгә чит татарлар түгел. Татарстан Язучылар берлеге, һич тә авырлык кичермичә, Октябрьский һәм Бәләбәй калаларына 4-5 әдипле десант озата, андагы иҗатчыларның әсәрләрен «сөреп» алтын бөртек таба һәм, ахыр чиктә, Казанга чакырып әдәби семинарлар да уздыра, талантларга юлны ача ала. Үзебез дә мич башыннан мәйдан уртасына сикереп төшмәдек бит, безне дә «Идел» лагеренда, башлангыч семинарларда «үтүкләп» шомарттылар. «Без бергә!» дигән шигарьне эштә раслап күрсәтергә вакыт...

Туймазыга чаклы барып, Фәнирнең туган авылы Түбәнәк янындагы «Бабай утары»н күрми китсәк, гөнаһ булыр иде. Йә Ходаем, наратлык урманындагы аланлык буенча эчкә сузылып кергән, ясалма күл һәм биеклекләр белән баетылган, балалар өчен 6-7 йортлы «Сәләт» лагерен да сыйдырырлык җәннәт почмагы да була икән! Кунаклар һәм балалар өчен мунча-душлары да, кичке табигать кочагында серләшеп утырырлык чатырлары, сабыйлар концертын гына түгел, зур юбилейлар үткәрерлек матур ашханәсе, күзәтеп туймаслык һәм санап бетергесез агач сыннары – һәммәсе бар. Әмма әлеге ял йортының йөзек кашы – XVII-XX гасырдагы татар йортлары белән лапасларын, Чуаштаннан кайтарып тергезелгән 1870 елгы борынгы тегермән һәм тимер алачыкларын, элеккеге арба-чаналарны, дистәләгән эш коралларын үз эченә алган «Бабай утары» бит! Ә аның артындагы күл һәм утарларга тупланган ике аккош, болан, фазан, йорт һәм урман тавыклары!..

● Балалар өчен дүрт сменада эшләүче лагерь йортлары.

Фәнир әфәндегә оҗмах почмагыдай ял йорты яки туган авылы Түбәнәктә 4 манаралы, 5 айлы мәчет, кымыз һәм казылык белән сату итүче кафе, урта мәктәп ихатасында тыл каһарманнарына багышланган һәйкәл, Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлары хөрмәтенә обелиск төзеп куярдай сәрмая күк йөзеннән яңгыр булып яумый. Аның әле Владимир токымлы, гомумсаны белән 150 баштан артык ат көтүен утлатып йөртә торган яланнары да бар. Дөрес, Фәнир дусның мондый уңганлыгыннан бигрәк үҗәт татарлыгы Уфадагы түрәләрнең үзәгенә үткән бугай инде. Алар Фәнирнең 360 гектарлы яланын якындагы бер авыл кешеләренә пай җирләре рәвешендә бүлеп бирергә ниятли. Ул чагында Фәниргә «Бабай утары» тирәсенә кайтып кысрыклану кала. Әмма ул бер тамчы да чигенәчәк түгел, аңа татарлыгы – яшәү, һава, Кояш!

Фәнир – безнең Бөгелмә районындагы Карабаш бистәсендә гомер итүче тагын бер үзенчәлекле эшмәкәр – Фәрит Нәбиуллин белән дә искиткеч дус. Кайту юлына чыккач, билгеле, без Фәрит утарларын, аның хуҗалыгын да урап үтә алмадык. Фәритнең фермалары

● Фәнир Галимов үзенең Түмәнәк авылында төзеп куйган 4 манаралы, 5 айлы мәчет.

● Фәнир Галимовның Владимир токымлы ат көтүе.

● Фәрит Нәбиуллин.

ТАТАР ИЛЕ

● Ял йортын бизәүче агач сыннар.

Лениногорск районы чигендә, Каран тау ышыгында урнашкан. Биредә суы меңнәргә мәгълүм Тархун белән игезәк чишмә һәм Фәрит үзе үк тыюлыкларга әверелдергән күлләр дә бар. Могҗиза түгелмени, Фәрит ул күлләргә форель, табан, толстолобик балыкларын җибәргән, быел тәүге тапкыр сөзү үткәрергә дә җыена. Ә хуҗа кеше өчен иң мөһиме: табуннар булып йөргән 500 гә якын татар аты шушы күлләргә су эчәргә, хәтта түземсезләре коенып чыгарга дип тә килә.

12 ел гомерен шушы татар атларын үрчетүгә биреп, Фәрит татар тарихы буенча да җанатарга әверелгән. Аның баскын Аксак Тимер белән ватанпәрвәр Туктамыш хан бәрелешләре, Болгар әмирлегенә 17 мең арба белән күчеп килгән Гәрәй кабиләсе, аларга ияргән кыргыз-казах, кыпчак ырулары турында сөйләве бик гыйбрәтле. 1798 елда Оренбург губернасының Уфа провинциясен кантоннарга бүлгәч, власть ияләренең кантоннарны йортларга бүлү һәм шулардан «башкорт» полклары таләп итү хәрәкәтенә дә үзенчәлекле бәя бирә. Мисалга, бүгенге Актаныш районының Байсар волосте авыллары – 11 нче кантон, ә Азнакай-Туймазы төбәгендәгеләр 12 нче кантон булып йөргән. Чип-чиста татар авылларында яшәүче ирләрдән төзелгән һәм яртысы Пруссия походларында, 1812 елгы Ватан сугышында, 1814 елның март аенда Парижны яулап алуда катнашкан шушы полкларны яки хәтта исеме белән үк типтәрнеке яисә мишәрнеке булган гаскәрләрне «башкортныкы» дип тарихка теркәп кую дөрес гамәлмени?!. Мондый хилафлык һәм мәкер тоюдан каберләрдә безнең ерак бабакайлар рухы-җаны елап ятмасмы соң?!.

Фәрит җаны-тәне белән татар булып яши, үзе башлаган эш белән дә чиксез горурлана. Аның маллары да бөтен Рәсәй буенча җирле токым атлары өчен бәйгеләрдә катнаша һәм күп очракта җиңү яулап кайта. Фәрит кайбер район сабан туйларына ат өстендә утырган килеш көрәшү бәйгеләрен кертеп җибәрә алуына да шатланып бетә алмый. «Хәтта яу походлары белән барган вакытта, юл өстендә дә татар ир-егетләре, атышмы яки көрәшме ул, беренчелек өчен бәйгедән туктап тора алмаган, шуңа күрә ияр өстендә килеш тә гайрәт ачыкламый калмаган бит алар», – дип үз бәясен ачыклап та куя.

● Каран тавы ышыгында Ф.Нәбиуллинның татар атлары.

● Фәрит атларының сусау басып рәхәтләнгән чагы.

● Ф.Нәбиуллинның Карабаш бистәсендәге хуҗалыгы.

Фәрит үзе дә искиткеч гайрәтле һәм тырыш. Аның 1920 еллар ахырында Карабаштан аерылып чыккан коммуна урынын өр-яңадан уята башлавы да, татар атлары һәм татарым дип яшәве дә сокландыргыч. Бирсен Ходай, ике асыл татар иренең һәм алар үстергән балаларның язмышы да бәхетле һәм җиңүле була күрсен иде!

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

СӘЯСӘТ ҺӘМ

«Тарих миңа карата мәрхәмәтле булачак... Чөнки мин аны үзем язачакмын», – ди У.Черчилль (1874-1965).

Бу вакытта ул, Дарданелла хәрби операциясе уңышсыз тәмамлану сәбәпле, Адмиралтействоның Беренче лорды вазифасыннан азат ителеп, провинциядәге Ланкастер герцоглыгы канцлеры вазифаларын үти башлый. Аның иң яхшы портреты да шул чорда ясала. Рәссам Уильям Орпен 1916 елда сәясәтчене аның иң авыр көннәрендә сурәтли. Черчилль әлеге портретны үзе үлгәнчегә кадәр аш бүлмәсендә элеп тота.

У.Черчилль 1915-1962 елларда 500 дән артык (күпләр 544 ди) картина яза. Алар төрле илләрдә шәхси һәм күмәк күргәзмәләрдә күрсәтелә. 1921 елда ул «Сынлы сәнгать вакытны сарыф итү буларак» дигән язмасын һәм 19 картинасын туплап, бер журналда бастыра. Автор язма өчен 1000 фунт стерлинг гонорар да ала. Дус рәссамы К.Монтаг: «Әгәр дә сез сәясәттә сәнгатьтәге кебек көчле икәнсез, Европа бөләчәк», – дип шаярта. 1925 елны тагын бер журнал өчен «Хобби» дип аталган статьясын яза, чөнки бу чорда Черчилль ярлы яши, парламентның түбән палатасында депутат эшчәнлегеннән кала, рәсми рәвештә эшсез булып санала.

Бүгенге көндә Черчилльнең күп кенә картиналары – шәхси тупланмаларда яисә нәсел дәвамчыларында. Аларның берникадәре Бөекбритания Милли фонды тупланмасында да бар. Ике әсәре Кембридж университетындагы Черчилльнең мемориаль кабинетында эленеп тора. Кайбер картиналары төрле музей һәм галереяларда саклана.

У.Черчилль башка рәссамнар өчен кызыклы шәхес булганга күрә, аның үзен сурәтләүчеләр дә күп була. Ләкин сурәт өчен вакыт табу һәм бер позада утырып тору гына сәясәтчегә авыр бирелә. Барыбер аны тасвирларга яраталар, мондый плакатлар бихисап. Тиз аралашучан кеше булганга, аның холкында йомыкыйлык та, тәкәбберлек тә күзәтелми. Ә менә Черчилль үзе портретлар язуга мөкиббән булмый.

Аның нәселендәге Мальбороның 1 нче герцогы Джон Черчилль заманында Европаның иң яхшы әсәрләрен, Рафаэль, Өлкән Питер Брейгель, Рембрандт картиналарын туплый. Кечкенә Уинстон да шул картиналарны күреп, сокланган, ахрысы. 1884-1886 елларда гаиләнең матди хәле какшагач, нәсел бу картиналарны башкаларга сатып җибәрә. Черчилльнең әнисе Дженни да картиналар язу белән мавыга. Бер картинасын Ирландиянең сынлы сәнгать җәмгыятенә дә юллый һәм берничә эшен сата. Лондондагы бер рәссам ханымнан дәресләр ала һәм шуларга кечкенә улын да алып баргалый.

Черчилльнең кызы Мэри Соумс: «Балачакта әти рәсем ясау белән мавыкмаган, аның моңа сәләте дә булмаган», – дигән. Черчилль үзе дә китапларында рәссамлыкка тартылуын расламый. Әмма укыган чакта әнисенә язган хатларына барыбер рәсемнәр, чәчәкләр ясаган. Мәктәп елларында журналдагы карикатураларны карарга яраткан. Өстәмә дәрес итеп рәсем дәресен дә сайлаган, рәсемнәрне атнасына сәгать ярым ясаган һәм армия классындагы өстәмә дәресләргә дә теләп йөргән. Пейзажлар ясый башлавына да сөенгән. Өченче тапкырында, ниһаять, Королеваның Сэндхерст хәрби академиясенә укырга кергәндә, ул рәсем буенча имтихан тотып, 500 баллның 339-ын җыйган. Ул чакта офицерлар рәсемнәр ясый белергә дә тиеш булган.

Ул 1895 елны Кубада Daily Graphic газетасы корреспонденты булып эшләгәндә, үз статьяларын ландшафт һәм сугыш рәсемнәре белән дә бизәгән.

Аның нәселендәге биш герцог күңел төшенкелегеннән җәфа чиккән. Вазифасы түбәнәйтелгәч, Черчилль дә депрессия халәтендә була. Депрессияне ул һәрвакыт бер атама белән – «Кара эт» дип атый. Күңелсезлеккә бирелмәс өчен Хэскомб авылындагы бер йортны арендага ала. Ул бу вакытта бар нәрсәгә битараф, кулларын болгый-болгый күз алдында булмаган зат белән сөйләшә. Һәм кинәт кенә рәсем ясый башлый. Ул үзе бу хакта болай ди: «Кырык яшемә җитеп, минем беркайчан да кылкаләмгә яисә каләмгә мөрәҗәгать иткәнем булмады. Моңа кадәр мин картина язуга аерым бер төр сер итеп карый идем».

1915 елның июнендә, Лондонда Уинстон мольберт, киндер, скипидар, бик күп майлы буяулар сатып алып, кибет киштәләрен бушата, имеш. Әмма кайбер туганнарының истәлекләрендә бу хакта сәнгать өчен бар кирәк-яракны җәмгате алып кайтып бирә, диелгән. Беренче киндерләргә ул үзләренең йорт фасадын, интерьерын ясый. Бик тә кыенсынып кына ясый башлаганда, аның янына рәссам Джон Лавериның җәмгате килеп туктый. «Курыкмагыз! Бирегез әле миңа кылкаләмне!» – ди ханым. Лединың бик кыю итеп буявын күргәч, Черчилльнең дә эчке комплекслары юкка чыга. «Шуннан бирле мин киндер алдында үземне кыюсыз хис итмәдем», –дип искә ала ул соңрак.

Бүген У.Черчилльнең ул чакта ясаган дүрт пейзажы саклана. Ул табигать кочагына чыгып, андагы матурлыкны язу белән мавыга. Бакчачылар аның киндерләрен, кылкаләмнәрен, палитрасын күтәреп бара. Кирәкле урын сайлап алгач, зонт кадап куела. Аннары ул хезмәтчеләрен кайтарып җибәрә, һәм берүзе калып, ясый башлый.

Уинстон моңа кадәр музейларга да йөрмәгән була, ә хәзер җәмгате аны Лондонның милли галереясына алып бара. Ул бер картина янында ярты сәгать буе басып торып, аның язу техникасына төшенергә тели. Икенче көнне тагын музейга китә. Картиналар язганда, сәясәт турында онытып торуына да игътибар итә. «Кайчак мин сынлы сәнгать белән шөгыльләнү хакына барсын да ташларга әзер», – ди.

1915 елның ноябрендә ул фронтка юнәлә, батальон белән җитәкчелек итә. Шуңа карамастан дүрт картина иҗат итә. Аның гадәттән тыш тыныч булуы солдатларны һәм офицерларны гаҗәпләндерә. Дошман уты астында рәсем ясап утырсын әле! 1916 елның маенда Черчилль Лондонга кайта. Мольбертлар, буяулар – һәрчак янында. Һәрбер йортта ул үз студиясен булдыра. 1917 елның июлендә аны кораллану министры итеп билгелиләр, 1919 елда ул инде хәрби министр һәм авиация министры итеп куела...

●Чартуэлл. Сарыклар белән пейзаж.

1921 елның мартында Каир конференциясе вакытында Уинстон, дөягә менгәндә, җиргә егылып төшә. Җәрәхәтләнүенә дә карамастан, барыбер Сахара күренешләрен сурәтли. Черчилль мисырлылар арасында популяр булмый. Алар аңа ташлар ата, сүгенеп каршы ала, ләкин Уинстон урам уртасына утырып, рәсемнәр ясавын дәвам итә һәм мисырлыларның янауларына җавап та бирми.

1930 еллардан башлап сәясәтче зур күргәзмәләргә рецензияләр язуны да үз итә. Аның «Чартуэллда алтын балыклы күл» әсәре 1932 елда иҗат ителә. Бу күлне ул гомере буе, вафат булганчыга кадәр яраткан. Анда мәңгә якын алтын балык йөзеп йөргән иң. Бервакыт инглиз рәссамы Г.Сазерленд (1903-1980) әңгәмә барышында сәясәтчедән ни өчен әлеге күлне ошатуы хакында сорашкан. «Шушы күлнең суларында мин үлгән кызым Мэриголдның йөзен күрә алам», – дип җавап биргән Уинстон. Кызчык ике яшь ярымда испан гриппы эпидемиясендә вафат булган. Әлеге картина Лондондагы 1948 һәм 1959 елгы күргәзмәләрдә дә күрсәтелгән. АКШ, Канада, Австралиягә дә алып барылган. Черчилль вафатыннан соң, 1977, 1982, 1983 елларда да экспозицияләнгән. Картинадагы су өсте – җанлы, яктылык та дөрес итеп сурәтләнгән. Бу картинаны күп рәссамнар әлегәчә мактый. Танылган шәхес яраткан күлен соңгы тапкыр 1962 елда ясаган, әлеге картинасын тән сакчысына бүләк иткән. Әсәр 2014 елны Сотбис аукционында 1 762500 фунт стерлингка сатылган.

1922 елда Черчилль утарын матур итеп үзгәрткән, күп кенә бакчаларның, сулыкларның проектларын үзе төзегән. Соңрак ул анда сәгатьләр буе картиналар язган. Йорттагы һәрбер бүлмәгә чәчәкләр куела торган булган, лаләләр, нарциссләр... Кайчак ул дус рәссамнарының киңәшләренә дә колак салган, аларның йогынтысына да бирелеп алган.

Актриса Вивьен Ли 1951 елның августында әлеге гаиләдә кунак була. Аның ире Л.Оливье хөрмәтенә бирелдә кечке аш оештыралар. Вивьен Ли утардагы бакчага соклана. 1960 елда төшерелгән документаль фильмда ул Черчилльнең аңа үз картиналарын күрсәтүе хакында сөйли: «Бер картина яныннан үткәндә мин аңа бик тә сокландым. Гаҗәеп, әмма сәясәтче шунда ук: «Сиңа бу әсәр ошыймы?» – дип сорады. Мин аңымны югалта яздым, нәрсә әйтергә дә белмәдем... Ул миңа бу картинаны Раштуага җибәрермен дип игълан итте. Әмма посылка ике атнадан соң ук килеп җитте, андагы хатта:

●Әл-Кутубия мәчете манарасы.

СӘНГАТЬ

«Мин Раштуаны көтеп җиткерә алмадым» дип язылган иде». Актриса дулкынланып аңа рәхмәт хаты сала. 2017 елда бу 51х36 см күләмдәге, имзалы әсәрне Сотбис аукционында 638750 фунт стерлингка сатып җибәрәләр.

1939-1945 елларда Черчилль сәнгать белән шөгыльләнүен туктата. 1943 елның гыйнварында Касабланкада «Зур ике»нең ун көнлек конференциясе уза. Аннары Черчилль Рузвельтка Марракешка барырга тәкъдим итә. Сәфәр дүрт сәгатькә сузыла, аларны утызлап хезмәткәр һәм сакчы саклый, күктә һәрби вертолетлар очып йөри. Алар Марракештан чыгып, Америка вице-консулы йортында тукталалар. Йортка терәлеп төзелгән традицион башняга менеп, карлы Атлас таулары фонындагы Кояш баешын күзәтәләр. Икенче көнне президент иленә кайтып китә, ә Черчилль тагын башняга менә һәм берничә сәгать буе кала панорамасын күзәтә, аннары киндер алып, сурәт ясарга керешә. Марракеш панорамасын, таулар фонындагы Әл-Кутубия мәчете манарасын… Картина матур булып килеп чыга. Чөнки анда тыныч тормыш тасфирланган. Якты хыял! Ул бу әсәрен ике көн дәвамында яза.Әл-Кутубия – XII гасырда әмир Якуб әл-Мансур тарафыннан төзетелгән Марракешның иң зур мәчете. Аның аталышы «Китапныкы» дип тәрҗемә ителә, мәчет урнашкан мәйданда китапханә дә, китап сату кибетләре дә булган, аның 69 метрлы манарасы каланың теләсә кайсы почмагыннан күренеп тора. Мәчет андалузия һәм марокко орнаментлары, җете мозаика белән бизәлгән.

«Әл-Кутубия мәчете манарасы» – Уинстонның сугыш вакытында язылган бердәнбер картинасы. Ул аны Рузвельтка бүләк итә. Соңрак картина төрле тупланмаларда саклана. 2011 елны Голливуд актеры Брэд Питт шушы әсәрне 2 950 000 долларга сатып ала һәм җәмәгате А.Джолига бүләк итә. 2021 елда картина Лондон аукционында 7 000 000 фунт стерлингка (11,5 млн. долларга) сатыла. Аны сатып алучы үзен белдертми, аукционда ул телефон аша гына катнаша.

Тарихи архитектуралы Марракеш темасына Уинстон тагын бер тапкыр әйләнеп кайта. 1948 елда «Әл-Кутубия манарасы»н тулысы белән диярлек кабатлаган «Марракеш» картинасы язылa. Аларның икесе дә Марокконың алсу һәм саргылт комлы палитрасын, аның белән контраст зәп-зәңгәр күкне чагылдыра. 1951 елда мәшһүр сэр аны тагын АКШ президентына, бу юлы Г.Трумэнга бүләк итә. Президент картинаның кызы өчен иң кыйммәтле бүләк иткәнен аңлап, 1972 елгача, үлгәнче саклый. Аннары әсәр кызы Маргретка күчә. 2007 елда «Марракеш» Сотбис аукционына гаять зур суммага сатуга куела.

1945 елны хөкүмәт башлыгы постыннан отставкага киткәч, Уинстон күп вакытын сәнгатькә багышлый. 1945 елның сентябрендә Италиягә бара. Аның шәхси табибе Черчилль кирәкле урын сайлап алгач, биш сәгать дәвамында картина яза иде, дип искә ала. 25 көн эчендә 15 картина иҗат итә. 1945 ел ахырында аңа Time нәшрият йорты җитәкчелеге исеменнән 75 000 долларга сәнгать хакында статьялар сериясе язарга тәкъдим ителә. Ләкин Уинстон аны кабул итмичә, язмалар урынына үз картиналарын бастырырга мөмкин булуын әйтә.

1948 елда аның язмалары картина репродукцияләре белән берлектә нәшер ителә һәм 50 мең данә китап бик тиз арада сатылып бетә. 1950 елда АКШта янә 25 мең данә китабы сатыла. Аны француз, немец, фин, япон телләренә дә тәрҗемә итәләр. Рәссам фикеренчә, киндерләргә тирә-юнь мохиттән әле генә рәссам күзе аша кабул ителгән сигнал күчерелә, сәнгати код, киндергә ул тамашачы өчен шифрланган криптограмма буларак беркетелә. Автор ясаганда бар табигать күренешләренең үзе өчен яңа мәгънә белән тулылануларын, кечкенә детальләрнең дә кешенең күңел халәтенә тәэсирле булуларын искәртә.

1931 елга кадәр сәясәтче беркайчан да картиналарына үз имзасын куймый. Аннары картиналарның күбесе имзалана башлый. Ике-өч эшенә ул «У.Ч» дип, ешрак «WSC» дип яза. Соңгы елларда аның картиналарына Лондон остасы Ф.Патриксон, рәссамның үз үтенече буенча, бакырдан шаблон имза ясап өсти. Тән сакчысы Уолтер Х.Томпсон аннан бер картинасын бүләк итүен үтенгәч, Черчилль, кыенсынып китеп: «Сайлап ал», – ди. Аннары тән сакчысы имза да куегыз инде дигән гозерен җиткерә. Әлеге сакчы Черчилльнең бик иртә сәгатьләрдә ясый башлавын һәм кичке җиде(г)ә кадәр ясавын да искәртә. Ул бары тик 1950 елларда гына картиналарын дусларына, якыннарына бүләк итә башлый. Бервакыт: «Минем картиналарым сату өчен бик начар, ә якын дусларымнан башкаларга бүләк итү өчен кыйммәт», – ди. Шулай да ул аларны Елизавета II гә, Рузвельтка, Г.Трумэнга, Д.Эйзенхауэрга, Бөекбритания премьер-министры Дэвид Ллойд Джорджка һ.б. бүләк итә. Моннан кала ун оныгының һәрберсенә дә берәр картина бүләк итеп чыга. Күп кенә замандашлары аны чын рәссамга санамый да. Күңелен юату өчен генә ясый иде бит ул, диләр. Черчилль үзе дә: «Мин һөнәри әдәбият белгече булуым белән горурланам, ә болай мин һәвәскәр рәссам гына», – дип искәртә торган була. У.Черчилль 1953 елда әдәбият номинациясе буенча Нобель премиясенә лаек була. Аның тарафыннан XX гасырдагы Бөекбритания тарихы хакында 7 китап нәшер ителә, автобиография, әтисенең биографиясе, «Малаканд кыр армиясе хакында повесть, 1897», ике томлык «Елга сугышы» китабы, «Саврола» романы, 4 томлык «Дөнья кризисы», «Мальборо тормышы», Икенче бөтендөнья сугышы хакындагы мемуарлар, «Инглиз телендә сөйләшүче халыклар тарихы» китабы!

Сэр никадәр тыйнак булырга тырышса да, барыбер үз картиналары каталогын төзәтә. «Сынлы сәнгать аның тормыш гобеленында бер җеп кенә иде. Муза аңа 1915 һәм 1945 елларда эшеннән куылгач, аннары инде 1955 елда, ниһаять, отставкага киткәч ярдәмгә килде бит», дип саный сәясәтчеләр. Күпләр ул картина язганда гына сөйләшми иде дип тә искәртә. «Мин үз картиналарымны гаиләдән башкаларга күрсәтергә кыенсынам. Алар минем өчен балаларым кебек, тыңлаусыз да була, әмма үзләрен кайгыртуны да таләп итә», – ди һәвәскәр рәссам.

Аның мактауларга бер дә исе китми. Хәтта гомеренең соңгы елларында да тән сакчысы Э.Мюррейның картиналары белән танышкач ук: «Беләсеңме, синең картиналарың минекеләргә караганда күпкә яхшырак. Ләкин синекеләр яхшы яклары буенча гына бәяләнә», – ди. Әмма сынлы сәнгатьне яхшы белүчеләр сәясәтченең иҗатына да югары бәя бирә. «Аның берничә дистә эше даһи импрессионистларның шедеврлары белән ярыша ала», диләр. Бу чыннан да шулай. Әйтик, дәүләт эшлеклесенең «Чартуэллдагы күлдә кара аккошлар» яисә «Чартуэлл. Сарыклар белән пейзаж» картиналарын гына алыйк. Соңгысы 2006 елны аукционда исеме ачылмаган коллекционерга1 млн фунт стерлингка сатылган!

Башка кешеләрнең фикерләрен белү өчен сәясәтче 1921 елда ук берничә картинасын Шарль Морен дип имзалап, Париждагы Дрюэ галереясында ачылачак күмәк күргәзмәгә юллый. Рәссамның алты картинасын диварга эләләр. Аның үзе янында басып торган бер сәнгать белгече бу картиналарны кырык минут буе анализлый. Аларның алтысы да утызар фунт стерлингка сатыла. Әмма имза моннан ике ел элек үлеп киткән пейзаж остасы Шарль Камиль Моренныкы (1849-1919) да була бит әле. 1925 елда Сандерлэндхауста һөнәри түгел, ә исемнәре алдан билгеле булмаган рәссамнар күргәзмәсендә дәүләт эшлеклесенең «Кышкы кояш яктысы» хезмәте I урынны яулый. Жюридагы иганәче Д.Дэвин әлеге картинаны һөнәри рәссам язган, ахрысы, дип борчыла хәтта. Бүләккә О.Бирли картинасы бирелергә тиеш булса да, ни өчендер картина Черчилльгә барып ирешми. Нәкъ 20 елдан соң О.Бирли сәясәтченең кызы Мэриның портретын иҗат итеп, вәгъдәсен үти. 1947 елда Уинстон Королеваның сәнгать академиясе күргәзмәсенә ике картинасын Дэвид Уинтер дип имзалап сала. 1948 елда аны әлеге академиянең почетлы әгъзасы дәрәҗәсенә лаек дип табалар.

1958 елда президент Д.Эйзенхауэр тәкъдиме буенча АКШта 35 картинадан торган шәхси күргәзмәсен ачкач, күргәзмәне ярты миллион тамашачы карый. Күргәзмә АКШның башка калаларында да, хәтта Яңа Зеландиядә дә күрсәтелә. Тик Питтсбургта, Цинциннати, Чикагода аның эшләре начар язылган дип бәяләнә, бу калаларда күргәзмәне күрсәтмәскә булалар.

Черчилльнең Бөекбританиядәге 62 картинасыннан торган беренче шәхси күргәзмәсе исә нибары 1959 елда, Лондонда ачыла. Күргәзмәнең соңгы көннәрендә генә дә аны 141 мең кеше карый. Әсәрләрне башка калаларда да күрсәтергә телиләр, әмма рәссам үзе: «Болай да картиналарым белән бик озакка саубуллашып тордым», – дип, мәдәни сәяхәт дәвамыннан баш тарта.

Мәшһүр шәхеснең кызы, актриса Сара да рәсем ясау белән мавыккан, оныгы Эдвина Сэндис та – рәссам, сынчы һәм иллюстратор. Бертуганының улы Джон Джордж Спенсер-Черчилль дә (1909-1992) рәссам һәм сынчы булган.

Гомумән, У.Черчилль картиналар язып, җанына рухи ләззәт җыйган һәм шаяртып: «Мин Күккә барып җиткәч, беренче миллион ел вакытымны рәсем ясап үткәрергә җыенам», – дип әйтә торган булган.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Биләргә игътибар

Татарстанның Алексеевский районында Биләр тарихи җирлегенең чикләре билгеләнәчәк, аны саклау һәм төзелеш алып бару өчен регламент таләпләре куелачак. Әлеге документ өлгесе турында бүген республиканың тарихи җирлекләрдә төзелеш алып бару комиссиясе утырышында сөйләштеләр.

Биләр җирлеге белән Татарстан Фәннәр академиясенең Археология институты мөдире Айрат Ситдыйков таныштырды. Аның сүзләренчә, әлеге үзгәрешләр Биләрдә төзелеш эшен бер тәртиптә алып барырга ярдәм итәчәк.

“Бу Биләрнең архитектур йөзен саклап калуга юнәлгән. Аның тарихи мохите үз эченә XVIII-XIX гасырга караган корылмаларны, X-XI гасырда башланган шәһәрне планлаштыру структурасының сакланып калган элементларын кертә. Шулай ук Россия кануннарына яраклаштырып, шәһәр белән нәтиҗәле идарә итү, төзелеш алып барганда ачык эшләү һәм хаталарны җибәрмәү мөһим”, – диде ул.

Биләр чикләренә бүгенге Биләр авылы да керәчәк. Аерым алганда, тарихи кыйммәткә ия булган 30 объект исәпкә алынган. Алар арасында тарихи-географик музей, мәдәният йорты һәм башка корылмалар да бар.

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов белгечләр һәм түрәләрне җәлеп итеп бер атна эчендә документларны килештерергә кушты. “Бу шәһәрнең йөзен, статусын сакларга һәм тарихи җирлек чикләрен билгеләргә ярдәм итәчәк. Бүген шәһәргә андый документларсыз эшәргә ярамый. Ул үсеш алырга тиеш”, – дип белдерде ул.

Киләчәктә Биләр тарихи җирлегендә “Алтын Дага” мәдәни-рекреация кластерын төзергә җыеналар. Аны архитектор Антон Кочуркин җитәкчелегендә эшләгәннәр. Төзелешнең төп өлеше тыюлык зонасында алып барылачак. Җирлекнең ландшафтына зур үзгәрешләр кертелмәячәк, барлык объектлар да агачтан ясалачак диелә. Корылмалар традицион болгар архитектурасы нигезендә юрталар рәвешендә эшләнер, татар нәкышләре белән бизәлер дип көтелә. “Алтын Дага” кластеры үз эченә җәмәгать үзәге, балалар мәйданы, сәхнә, мунча, күпер, кунак йортлары, чатыр аланы һәм башка төзелеш объектларын ала.

Соңгы елларда татар җәмәгатьчелеге, галимнәр Биләргә Татарстан җитәкчелегеннән игътибар юк дип әйтеп килә. ЮНЕСКО исемлегенә кергән Зөя утравы белән Болгар гына абруйда, ә Биләр – үксез бала кебек дигән борчылулары белдерә. Биш ел элек Археология институты җитәкчесе Айрат Ситдыйков борынгы Биләр шәһәре ЮНЕСКО исемлегендә булырга тиеш дип белдерде. Бу фикерне Биләр тарихының төп белгечләре булган галимнәр Әнвәр Хәйри һәм Фаяз Хуҗин да инде күптәннән әйтеп килде.

Репрессияләр

Тарих шаһит: гаять дәрәҗәдә күп санлы, әмма бер гаепсез татар хәрбиләре Сталин тарафыннан үткәрелгән канлы репрессияләргә эләгә.

Якуб Чанышев.

Аларның иң күренеклеләреннән берсе – комдив (1935) Якуб Чанышев. 1937 елның 12 июнендә Ленинград хәрби округы командующие урынбасары, өч Кызыл Байрак ордены кавалеры комкор Виталий Примаков тарафыннан ягылган нахак яла аркасында ике ел ярым НКВД төрмәләрендә газап чигү Якуб Җиһангир улының сәламәтлегенә һәм хәрби карьера үсешенә коточкыч зур зыян сала. Аңа ташланган гаепләрдән чәчләр үрә торырлык: ул мәгълүм 58 нче маддәнең 2 нче һәм 11 нче бүлекләре буенча, милли террор кулланып баш күтәрергә әзерләнүче татар хәрбиләреннән торган яшерен оешма җитәкчесе сыйфатында җәбер-җәфа күрә. Дөрес, ул чордагы вәхшилекләр өчен язмышы фаҗигале тәмамланган Виталий Марковичны гына гаепләү урынсыз. НКВД подвалларында андый “фаш итү”ләргә нинди юллар белән ирешкән булулары сер түгел хәзер. Соңгы елларда соры кардинал Суслов роленә кергән Мединский тарафдарлары никадәр генә көчәнмәсен һәм кылынган явызлыкларын аклап, үзен күкләргә чөеп мактарга тырышмасын, узган гасырның 1930 елларында рәхимсез рәвештә үткәрелгән репрессияләр өчен төп гаепле кеше – Сталин. Кайберәүләрнең: “Янәсе, ул үзе урыннарга барып атып, сатып йөрмәгән”, – дип, аны яклап маташулары көлке. Андый сәер фикер сөреше белән Гитлер, Пол Пот кебек тираннарны да “аклап” булуын истән чыгарырга ярамый.

Әле Гражданнар сугышында ук 1 нче Идел буе аерым Татар укчы бригадасы комиссары булган, М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең махсус факультетын (разведка) тәмамлаган, 1926–1932 елларда – 1 нче Казан укчы һәм 1935-1937 елларда Урта Азия хәрби округындагы 6 полктан торган 68 нче Кызыл Байраклы укчы-тау дивизияләре белән командалык иткән комдив чиныңдагы Якуб Чанышевның 1940 елның июнендә ким дигәндә, генерал-майор буласы тамчы да шик уятмый. СССР Халык Комиссарлары Советының 1940 елның 4 июнендә дөнья күргән карары нигезендә Кызыл Армиядә хезмәт итүче 10 комдив хәттә генерал-лейтенант званиесе ала. 1939 елның декабрендә акланган һәм кабаттан комдив званиесе кайтарылган милләттәшебез исә, Бөек Ватан сугышы башланганчы, М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең гомуми тактика кафедрасында өлкән укытучы вазифасын башкара, фәкать 1942 елның 1 октябреннән генә генерал-майор погоннарын тага, 1944 елның 22 февраленнән – генерал-лейтенант званиесендә. Әлбәттә, Якуб Җиһангир улының Бөек Ватан сугышында погоннарындагы йолдызларының күбрәк буласын һәм, һичшиксез, армия командующие вазифасына ирешәсен дә фаразларга мөмкин. Татар каһарманының үзе оештырган 96 нчы Кызыл Байраклы Брест укчы корпусы белән командалык итеп, үзен хәрби данга күмүе, 1945 елның февраль һәм апрель айларында ике Ленин ордены белән бүләкләнүе, Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителүе – шуңа саллы дәлил.

Сугышка кадәр татар хәрбиләре арасыннан комдив дәрәҗәсенә ирешкән тагын бер милләт баласы, литва-поляк татары Искәндәр Тальковскийның язмышы тагын да фаҗигалерәк тәмамлана. Ул 1894 елның 18 сентябрендә Келецкий губерниясенә караган Меховской өязендәге Новобжевск бистәсендә туа. Губерния исә Россия империясенең Привислянский крае (Польша патшалыгы) составына керә. Әти-әниләре чыгышлары белән, икесе дә Кырык Татар авылыннан: Елизавета Степановна – авыл укытучысы, Искәндәр Госман улы – патша армиясе генерал-майоры. Искәндәр туганда әтисе чик отряды командиры булып хезмәт итә, званиесе – штаб-ротмистр. 1902 елдан Керчь махсус чик буе бүлеге командиры вазифасын башкаручы полковник И.Тальковскийның Карск һәм Кара диңгез бригадаларында яшерен тикшерү үткәрүе мәгълүм. 1906 елның июнь башыннан ул инде – командующие артиллерия генералы Александр Свиньин булган Аерым чик сагы корпусының VI округы составындагы 25 нче Кара диңгез чик буе бригадасы командиры. Дүрт ел ярым чамасы шул вазифаны башкарган чорда милләттәшебезгә генерал-майор званиесе (6.12.1910) бирелә һәм ул 1912 елның 31 маеннан штабы Рига каласында урнашкан 1 нче Санкт-Петербург чик буе округының 4 нче Рига бригадасы командиры булып хезмәт итә. Татар энциклопедиясендә ташка басылганча, “1915 елдан Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында: Виндава каласындагы гарнизон һәм Виндава отряды башлыгы, соңрак Балтыйк яр буе сакчылар отрядының Виндава районы башлыгы. 1916-1918 елларда Петроград һәм Двина хәрби округлары штаблары каршындагы хәрби хезмәткәрләр әзерләүче запас гаскәрләрдә” (5 том, 453 бит).

Башка тарихи чыганакларда 1917 елның 1 мартына генерал Тальковскийның 6 полкны берләштерүче 25 нче запастагы пехота бригадасы башлыгы вазифасында булуы раслана. Кайбер чыганакларда 1916 елның февраленнән 1918 елның июненә кадәр аның Петроград хәрби округы штабы карамагында торуы һәм бераздан 5 нче армия командующие кул астына җибәрелүе турында да мәгълүмат бар. 1917-1918 елларда армия Төньяк фронт составына керә, хәлләр кискенләшү нәтиҗәсендә бер елдан артык чорда җиде командующий алмашына. Ахырдан, 1918 елның гыйнвар-март айларында армия белән, яңа хакимият ягына авышкан эстон милләтендәге генерал-майор Артур Августович Зальф командалык итә. Мантыйк буенча фикер йөрткәндә, генерал-майор Искәндәр Тальковский да нәкъ менә 5 нче армия составында Октябрь таңын каршылый һәм 1918 елның июнь аеннан Кызыл Армия сафларына баса. Әүвәл Петроградтагы 1 нче укчы дивизия составындагы 1 нче бригада командиры, бер үк вакытта Петроград хәрби округының Мөселман хәрби советы Башкарма комитеты әгъзасы да булып тора. Искәндәр Госман улы 1919 ел башыннан Татар иле башкаласында: февраль аеннан – Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең 1 нче Казан мөселман пехота команда курслары мөдире. Мөселманнардан кызыл командирлар әзерләүне күз уңында тотып ачылган курслар, шул болгавыр чорда таратылган Казан хәрби училищесы базасында оеша. Әмма фронтта хәлләр кискенләшү сәбәпле, апрель аенда курсларны тулы составта Көнчыгыш фронтка озатырга мәҗбүр булалар, аның урынына 25 июльгә исә, 2 нче Казан Мөселман пехота команда курслары оеша. 1922 ел тәмамланып килгәндә курслар таратыла һәм аның базасында 6 нчы Берләштерелгән Татар-башкорт команда мәктәбе ачыла. 1937 елның 16 мартында хәрби уку йорты кабат исемен алыштыра һәм Татар АССР Үзәк башкарма комитеты исемендәге (1939 мартыннан – Татар АССР Югары Советы) Казан пехота училищесы дип атала башлый, 1941 елдан – Казан танк училищесы. Димәк, 1 нче һәм 2 нче Мөселман пехота команда курслары мөдире милләттәшебез Искәндәр Тальковский, һичшиксез, бу бай тарихлы хәрби уку йортының беренче җитәкчесе саналырга хаклы.

1920 елның августында, авырый башлаган генерал Тальковскийны Бакуга күчерәләр һәм Әзәрбайҗан җыелма хәрби мәктәбенә мөдир итеп куялар. 1921 елның башында 11 нче армиянең архив башлыгы булып хезмәт итә, шул елда бакый дөньяга күчә. Шунысы үзенчәлекле: улының да язмышы, гомеренең шактый өлеше Казан белән бәйле. Беренче тапкыр ул ата-бабалары җиренә 1919 елның гыйнвар аенда аяк баса, аңа – әтисе мөдир булып торган 2 нче Мөселман пехота команда курсларында саф буенча башлык вазифасын башкару йөкләнә. 1913 елда Рига каласындагы Алексан-

дәһшәте

●Искәндәр Госман улы Тальковский.

● Искәндәр Искәндәр улы Тальковский.

дрия гимназиясен тәмамлаган һәм этисе кебек хәрби булырга карар кылган Искәндәр Тальковский шул ук елны Петербургтагы Павлов хәрби училищесына укырга керә. Беренче бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, укуын вакытыннан алда, 1914 елның 1 октябрендә тәмамлап чыккан яшь подпоручик 2 нче гвардия пехота дивизиясе составындагы Павлов лейб-гвардия полкының запас батальонына ярымрота командиры итеп билгеләнә.1915-1917 елларда үзе хезмәт иткән Павлов полкы составында Төньяк-Көнбатыш, Көнбатыш һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларда сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, башкарган вазифалары – ярымрота командиры, атлы разведчиклар командасы башлыгы, батальонның уку командасы башлыгы һәм командиры.

Февраль революциясеннән соң үзе хезмәт иткән полктагы солдатлар комитеты рәисе урынбасары итеп сайлана, аннары – 2 нче гвардия пехота дивизиясенең мөселман солдатлардан торган комитеты рәисе. Көньяк-Көнбатыш фронтның армия һәм фронт күләмендә үткәрелгән мөселман солдатларының съездларына делегат итеп сайланган подпоручик Искәндәр Тальковский Октябрь революциясеннән соң Кызыл Армия сафларына баса һәм Петроград Хәрби мөселман советы чакыруы буенча, милли частьлар оештыру өчен Петроград хәрби округы командующие подпоручик Владимир Антонов-Овсеенко (репрессия корбаны, 1938 елның 8 февралендә атып үтерелә) карамагына юллама ала. Тальковский революция бишегенә декабрь башларында килеп җитә һәм округның кыр идарәсе комиссары, 1918 елның мартына кадәр командующий вазифасын вакытлыча башкарачак Константин Еремеевның шәхси боерыгы буенча солдатлардан һәм кала заводларындагы татар эшчеләреннән мөселман полкы оештыра. Ул оештырган мөселман полкы Петроградның ныгытылган районын көчәйтә, башкаланы саклауга саллы өлеш кертә. 1918 елның июленнән ул инде – шул ныгытылган район составына керүче 1 нче Петроград эшче укчы дивизиянең 2 нче укчы полкы командиры, яңа елдан – Казанда.

Тарих фәннәре докторлары Яков Гришин белән Дамир Шәрәфетдиновның “Гасырлар авазы” журналындагы документаль-тарихи хезмәтләрендә Искәндәр Искәндәр улының 1919 елның маеннан 1920 елның мартына кадәр 1 нче аерым Идел буе татар укчы бригадасының штаб башлыгы булуы һәм 1920 елның мартыннан Фирганә белән Семиречьеда 4 нче һәм 6 нчы кызыл коммунарларның аерым Төркестан укчы бригадалары белән командалык итүераслана. Гәрчә бригада белән бер ел командалык иткән Йосыф Ибраһимовның Төркестан фронты Реввоенсоветы әгъзасы итеп үрләтелгәч, аның урынына Искәндәр Тальковский билгеләнүен дә исәптән чыгарырга ярамый.

1923 елның сентябрендә Искәндәр Тальковский РККА Югары команда составының Югары хәрби-академик курсларын тәмамлый һәм 1 нче октябрьдә Берләштерелгән Татар-башкорт хәрби мәктәбенең башлыгы итеп билгеләнә. Тарихчылар Гришин белән Шәрәфетдинов ассызыклаганча, милләттәшебез 8 ел шушы вазифада хезмәт итү чорында республиканың иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша: Казан кала Башкарма комитетының барлык чакырылышларының һәм 1924-1931 елларда Татар АССР Үзәк башкарма комитетының әгъзасы булып сайлана. 1928 елда РККА оешуга ун ел тулу уңаеннан үтүче тантаналар вакытында Идел буе Хәрби округы Реввоенсоветының һәм ТАССР Үзәк башкарма комитетының мактау грамотасына лаек була. Шул ук елда Идел буе хәрби округы командующие Г.Д.Базилевич (патша армиясе подполковнигы, комкор Георгий Дмитриевичны 1939 елда атып үтерәләр) белән Реввоенсовет әгъзасы М.С.Дуганов имзалары төшкән аттестациядә Тальковский җитәкчелек иткән мәктәпнең яхшы хәлдә булуы, ә башлыкның үзен Югары команда составы курсларына җибәреп кайтаруның максатка ярашлы икәне күрсәтелә. 1929 елның гыйнвар-май айларында Хәрби академия каршындагы курсларда хәрби белемен камилләштереп кайткан Тальковскийның үзе башкарган вазифага лаек булуы, укчы дивизия белән командалык итәргә әзер икәнлеге бер үк вакытта СССРның Хәрби һәм диңгез эшләре буенча халык комиссары белән Реввоенсовет Рәисе вазифаларын башкарган Климент Ворошилов тарафыннан расланган карарда ташка басылган.

1931 елның 30 апреленнән Искәндәр Тальковкий – 3 нче Кырым укчы дивизия командиры, бер үк вакытта дивизион округның командующие вазифасын да башкара. Бу вазифада 1931 һәм 1934 елларда ике аттестация үтә, тагын бер елдан – комдив званиесендә. Мәгълүм булганча, Кызыл Армиядә, аңарчы категорияләрдә күрсәтелүче званиеләр нәкъ менә 1935 елның көзеннән кертелә башлый, “генерал” патша заманы архаизмы саналганлыктан, полковниктан югары чиннар “комбриг”, “комдив”, “комкор”, “командарм” атамаларын ала. Фәкать К8 категориясендә йөртелүче подполковник кына кирәксез дип табыла, әмма 1939 елның 1 сентябрендә Кызыл Армиядә андый звание дә гамәлгә керә. Биредә дә Тальковский иҗтимагый-сәяси тормыштан читтә калмый: Кырым АССР Үзәк башкарма комитеты президиумы әгъзасы итеп сайлана, грамоталар һәм “Маузер” пистолеты белән бүләкләнә. Ә инде СССРның 1936 елның 16 августындагы Үзәк башкарма комитеты карары белән Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән комдив Тальковскийның дивизия командиры вазифасындагы эшчәнлеге чираттагы аттестациядә югары бәяләнә.

Әмма 1937 елда илдә башланып киткән вәхшәтле репрессияләр шаукымы безнең милләт баласын да әйләнеп үтми. Бар да әүвәл Харьков хәрби округының сәяси идарәсе башлыгы дивизия комиссары званиесендәге (комдивка тин) Николай Блуашвилиның (1937 елның 8 ноябрендә кулга алына, 1938 елның 23 сентябрендә Грузия ССР НКВДсы “өчлеге” тарафыннан үлемгә хөкем ителә һәм ике көннән атып үтерелә) комдив Искәндәр Тальковскийга карата язган характеристикасыннан соң башланып китә. Заказ буенча язылганлыгы тамчы да шик уятмаган характеристикада комдивның иң төп гаебе итеп партия тормышы белән кызыксынмавы, гомумән, бөтенләй партиясез кешене хәтерләтүе ассызыклана. Җитмәсә, ул контр-революционер-троцкийчы Гецовның гаилә дусты да икән әле. Нәтиҗә бер генә: күптән түгел генә фаш ителгән халык дошманы, үз урынбасары Незлен белән дә шундый ук мөнәсәбәтләрдә булган Тальковский, һичшиксез, вазифасыннан бушатылырга тиеш. Әлбәттә, мондый ялган әләк җавапсыз калмый: 1938 елда Искәндәр Тальковскийны партиядән чыгаралар, армиядән куалар һәм кулга алалар. Ике ел буена газаплап та “гаебен” исбатлый алмагач, 1940 елның маенда ирекккә чыгаралар һәм рухы сынмаган, әмма этисе шикелле үк “генерал” званиесе йөртү хокукы киселгән (гәрчә Татар энциклопедиясендә хата белән И.И.Тальковскийның 1931 елдан генерал-майор булуы күрсәтелә – 5 том, 453 бит) комдив М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең башлык урынбасары итеп билгеләнә. Әмма бер елдан кабат кулга алалар, элек белдерелгән гаепләүләргә нигезләнеп 1942 елның 13 февралендә үлем карары чыгаралар һәм Кызыл Армия оешуны бәйрәм иткән көнне атып үтерәләр. Күп газаплар күргән милләт баласы, фәкать Хрущев “җепшек”леге нәтиҗәсендә, 1956 елда аклана.

(Дәвамы киләсе санда).

Рәис ЗАРИПОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

10 сентябрь (шимбә). ***Сәфәр аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 18.43 сәгатьтә калка, 5.54 сәгатьтә бата. 12 сәгать 58 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 13.09 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Аллергиядән – мумие

1 г мумиены 1 л җылы суда эретәләр. Көненә 1 тапкыр иртән эчәләр: 1-3 яшьлек балалар – 50 мл, 4-7 яшьлекләр – 70 мл, 8 яшьтән өлкәнрәкләр – 100 мл. Аллергия көчле булса, көндез дә эчәргә кирәк, әмма микъдарны икеләтә киметү зарур. Экзема интектергәндә, 1 г мумиены 100 мл суда эретеп, тирегә сөртәләр. Дәва курсы 20 көннән дә кимрәк булмаска тиеш.

11 сентябрь (якшәмбе). ***Сәфәр аеның 15 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,18.51 сәгатьтә калка, 7.22 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.06 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Ай һәм туклану

Ай ут билгеләрендә чакта (Кучкар, Арыслан, Укчы) организмның аксымга ихтыяҗы зур. Ай җир билгеләрендә булганда (Үгезбозау, Кыз, Кәҗәмөгез) тозны чамалап куллану кан составына уңай тәэсир ясый һәм буыннарга тоз утырудан саклый. Ай һава билгеләрендә вакытта (Игезәкләр, Үлчәү, Сукояр) организмның бигрәк тә үсемлек майларына ихтыяҗы арта. Ай су билгеләреннән узганда (Кысла, Чаян, Балыклар) организмга углеводлар күбрәк кирәк.

12 сентябрь (дүшәмбе). ***Сәфәр аеның 16 нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,18.59 сәгатьтә калка, 8.48 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.01 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашу вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы. Ай Кучкарда чакта сизү әгъзалары һәм башны дәвалау нәтиҗәле.

13 сентябрь (сишәмбе). ***Сәфәр аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,19.07 сәгатьтә калка, 10.13 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.56 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Инфарктлан – укроп

Вак кына туралган укроп белән петрушканы тигез микъдарда кушып, шуның 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суга салалар, сүрән утта 20-30 минут җылытып, суынганчы төнәтәләр. Көненә 2 аш кашыгы эчәләр. Дәва курсы – 22 көн. 1 ай ял иткәч, тагын 2 ай буе эчәләр. Аннан соң кабат 1 ай ял итәләр һәм инде даими рәвештә көнаралаш 2 шәр аш кашыгы эчәләр. Йөрәге авырткан кешегә сирень, дүлөнә, эвкалипт исен иснәү файдалы.

14 сентябрь (чәршәмбе). ***Сәфәр аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,19.18 сәгатьтә калка, 11.37 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.52 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Дарулы икмәк

Йөрәк авыртканда, 1 телем ипине дүрткә бүләләр дә, көненә 4 тапкыр, ашыкмый гына чәйнәп, 3әр тамчы валериана тамызылган чирегешәр телемне ашап куялар. Валериана үләне салынган ваннада коену йөрәк тибеше ешлыгын нормальләштерә. Сөтле яшел чәй эчү дә бик файдалы.

15 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Сәфәр аеның 19 нчы көне.20 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,19.31 сәгатьтә калка, 12.58 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.47 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

16 сентябрь (җомга). ***Сәфәр аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,19.50 сәгатьтә калка, 14.14 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 12.43 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Сарымсаклы ташкабак

3 кг ташкабак, 350 шәр г томат пастасы һәм үсемлек мае, 1 әр стакан шикәр һәм су, ярты стакан издерелгән сарымсак, 1 чәй кашыгы төелгән кара борыч, 2 аш кашыгы 70 процентлы серкә эссенциясе, 2 аш кашыгы тоз кирәк. Ташкабакның кабыгын әрчеп, иттарткычтан чыгаралар. Шуңа томат пастасы, үсемлек мае, су, шикәр, тоз кушып, кәстрүлдә 30 минут пешерәләр. Аннан соң сарымсак, борыч, серкә өстиләр дә, тагын 10 минут пешерәләр. Кайнар килеш стериль банкаларга тутырып, тимер капкач белән каплыйлар.

Югалган хәзинәләр

Көннәрдән бер көнне Җәбраил Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм янына саубуллашырга килеп, сәлам әйтте. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм үлем түшәгендә соңгы сәгатьләрен кичерә иде. Ул Җәбраил галәйһис-сәламнән сорады:

– Йә, Җәбраил, син бу дөньяга мин үлгәннән соң тагын киләсеңме?

Җәбраил галәйһис-сәлам җавап бирде:

– Йә, Аллаһ илчесе, миңа бу дөньяга Синең үлемеңнән соң төшүдән мәгънә юк. Ләкин тагын ун тапкыр төшәм һәм ун хәзинәне алам, диде.

1. Җир йөзендәге бәрәкәтне алам (вакыт бәрәкәте, ягъни вакытның кыскаруы. Бер ел бер ай, бер ай бер атна, бер атна бер көн, бер көн бер мизгел кебек үтәр). Бүген исә без моны ачык сизәбез.

2. Кешеләр арасында булган мәхәббәтне алам, ягъни мөселманның кардәшенә карата булган яратуы кими бара.

3. Туганнар арасында булган мәрхәмәтне алам. Туганнар арасындагы мөнәсәбәт суына барганын беләбез. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Туганнар арасын өзгән кеше җәннәткә кермәс».

4. Хатын-кызның оятын алам. Күп кенә хатын-кызларыбыз гаурәтләрен ачып йөрүе бүгенге көндә афәткә әйләнә бара. Шуның аркада күпме гаиләләр таркалып, җәмгыять какшый. Шуңа күрә хатын-кыз тәрбияле, әхлаклы булса, җәмгыять төзек булыр. Ә киресе күзәтелсә, җәмгыять җимерелер.

5. Фәкыйрьләрнең сабырлыгын алам. Алар сабырлыкларын югалтып, Аллаһка тәвәккәлләүдән туктап, Аның кодрәтендә шикләнеп, кешегә мөрәҗәгать итеп, үзләренең зарын яудыра.

6. Байларның юмартлыгын алам. Ягъни кешеләр бүген баеган саен, байлык артыннан куып яшәүләрен дәвам итә, зәкят түләми, мохтаҗларга ярдәм итми. Бармак белән санаулы кешеләр генә ярдәм кулы суза. Әгәр һәрбер бай кеше үзенең тиешле зәкятен түләсә, мохтаҗлар калмас иде.

7. Хөкемдарларның, ягъни ил башлыкларының, патшаларның гаделлеген алам. Ягъни кайбер дәүләтләрдә халыкларына карата булган гаделсезлекләр, кыерсытулар, золымнар – моның ачык мисалы. Үзләре тук була торып, ач кешенең хәлен белмәүләре аяныч.

8. Галимнәрнең тәкъвалыгын алам. Ягъни үзләренең ихтыяҗларына муафыйк булган фәтвалар чыгару, Коръән белән гамәл кылмау, аларны үзе аңлаганча халыкка шәрехләү, ягъни хакыйкый галимнәрнең китапларына мөрәҗәгать итмәү. Коръәнгә һәм сөннәткә туры килмәгән гамәлләр кылу. Пәйгамбәребезнең хәдисенә нигезләнеп, гыйлемнең ике төрле булуын беләбез. Берсе – телдәге гыйлем. Ул гыйлемнең файдасы юк. Икенчесе – йөрәктәге, калебтәге гыйлем. Монысы – файдалы гыйлем. Шуңа күрә алган гыйлемең белән гамәл кылу бик тә мөһим. Ихласлык һәм гыйлем бергә булырга тиеш.

Гали ибн Әбу Талиб әйтте: «Шундый бер заман җитәр. Исламның исеме генә, Коръәннең рәсеме генә калыр. Бу халыкларга галимнәр килер. Алар бик күп белер. Әмма белгәннәре белән гамәл кылмас».

9. Коръәнне алам. Ягъни шундый заман җитәр: мөселман кешесе иртә белән Коръән укыйм, дип уянган вакытта, Коръән битләре буп-буш булыр. Шунда ук гаҗәпләнеп, куркып күршесенә керер, аның да Коръәне буш булыр. Өч көн дәверендә ятлаган Коръән аятьләре йөрәктә булыр, телдә сакланыр, әмма өч көннән соң кеше «әлхәмдулилләһ» дигән сүзне дә искә төшерә алмас. Шуңа күрә Аллаһ биргән бөек нигъмәтне – Коръәннең бүгенге көндә кадерен белеп, хөрмәтләп, аны укып, аның буенча яшәргә омтылырга кирәк.

10. Кешеләрнең иманын алам. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Кыямәт җитмәс, җир йөзендә Аллаһ сүзен әйтүче булганда». Кыямәт алдыннан Аллаһ Тәгалә бөтен мөселманнарның җаннарын җиңел җил белән алыр. Шунда җир йөзендә Аллаһны зикер кылучы бер кеше дә калмагач, бу дөньяның әһәмияте калмаячак.

Шушы атап киткән ун хәзинәдән, уйлап карасак, соңгы икесе генә калды. Ягъни иман белән Коръән. Аллаһ иң кадерле булган ике җәүһәребездән файдаланып калырга насыйп итсә иде.

Тимергали хәзрәт ЮЛДАШ.

Ифтира

Ифтира ул – кешене урынсызга гаепләү, ялган сүзләр белән кешенең дәрәҗәсен төшерү, һич булмаган хәлләр сөйләп, халык алдында кешенең исемен пычрату.

Ифтира, ягъни яла ягу, ислам динендә хәрамнардан санала, чөнки ифтира мәгъсум (гөнаһсыз) кешеләрне авыр хәлдә калдыра. Кем турында булса да сөйләгәндә, ул сүзләрнең иясенә барып ирешүе турында да уйларга кирәк. Шуның өчен халык «Тугыз мәртәбә уйла, бер мәртәбә сөйлә», – дигән. Халыкның «тел пычактан үткендер» һәм «пычак ярасы төзәлер, тел ярасы төзәлмәс» дип әйтүе дә юкка түгелдер.

Тел белән эшләнгән зур гөнаһларның берсе – яла ягу. Әгәр дә телеңә хуҗа була белмәсәң, бу бик күп бәла һәм гөнаһларга сәбәп булырга мөмкин. Шуның өчен әби-бабаларыбыз: «Телчән теленнән табар», – дигәннәр дә инде.

Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Шик юк, адәм баласының хата вә гаепләренең күбесе теленнәндер».

Бу нисбәттә ислам галимнәренең түбәндәге кисәтүләрен искә төшереп китү урынлы булырдыр: «Ашаган вакытта авызга кабасы нәрсәгезгә дикъкать иткән, зарарлы вә начар нәрсәләрне ашамаска тырышкан кебек, авыздан чыккан сүзләргә дә дикъкать итеп, сүзләребез белән башкаларга зарар итмәү – әхлакый вазифаларыбыздандыр».

Ислам дине мондый хәлләрдә безгә аеруча игътибарлы булырга, һәр әйтелгән сүзгә ышанмаска куша. Мәсәлән, Коръәндә мондый юллар бар: «Тулысынча билгеле булмаган нәрсәләргә иярмәгез. Чөнки Кыямәт көнендә колагыңнан, күзеңнән һәм кальбеңнән сораячаклар» («Бәни Исраил», 17:36).

«Әй мөэминнәр, әгәр сезгә яман, шикле бер кеше ниндидер хәбәр китерсә, ул (әшәке, ара бозучы) кешенең хәбәрен тикшермичә, аңа ышанмагыз. Әгәр бу кешегә ышансагыз, үзегез дә белмичә бер төркем кешегә (бер җәмәгатькә) зыян китерерсез, аннан соң, дөреслекне аңлагач, бик нык үкенерсез» («Хүҗүрат», 49:6)

Эшләнгән явызлык-усаллыклар беркемгә дә табыш булып кайтмый. Башкаларга зарар иткән кеше, бу җирнең өсте һәм асты бар икәнен онытмасын иде. Башкаларга явызлык кылганнарга бу дөньяда качып калыр өчен урын да табылыр, ләкин ахирәт тормышында андыйлар беркая да качып котыла алмаслар.

Нәрсә көчлерәк?

Аллаһы Тәгалә Җирне яраткач, ул һәрвакыт тетрәп торган, шуннан соң Аллаһ тауларны яратып, алар белән Җирне ныгыткан. Фәрештәләр тауларның көченә таң калып: «Йә Рабби, Синең мәхлукатларың арасында таулардан да көчлерәк берәр нәрсә бармы?» – дип сораганнар. Аллаһ: «Әйе, бу – тимер», – дип җавап кайтарган. Алар янә: «Йә Рабби, Синең мәхлукатларың арасында тимердән дә ныграк һәм көчлерәк берәр нәрсә бармы?» – дип сораганнар. Аллаһы Тәгалә: «Әйе. Бу – ут», – дип әйткән. Фәрештәләр: «Йә Рабби, Синең мәхлукатларың арасында уттан да көчлерәк берәр нәрсә бармы?» – дип сораганнар. Аллаһ: «Әйе, бу – су», – дип җавап биргән. Шуннан фәрештәләр: «Йә Рабби, Синең мәхлукатларың арасында судан да көчлерәк берәр нәрсә бармы?» – дип сораганнар. Аллаһы Тәгалә: «Әйе. Бу – җил», – дип әйткән. Фәрештәләр: «Йә Рабби, ә җилдән көчлерәк берәр нәрсә бармы?» – дип сораган. Аллаһы Тәгалә: «Әйе. Бу – уң кулы белән биргән сәдакасын хәтта сул кулыннан да яшерүче кеше», – дип җавап кайтарган.

Әмирнең ил тотар солтаннары

● Миндар Әгъләмов.

Дәүләтчелеген югалткан татар халкының рухи үсешен гасырлар буена аның үз арасыннан чыккан хәлле кешеләре – байлар, зур сәүдәгәрләр кайгыртып торган. Алар үз акчаларына милли мәктәпләр тоткан, китаплар чыгарган, газета-журналлар нәшер иткән, мәчетләр салдырган. Үтәмешовлар, Апанаевлар, Дәрдемәндләр һ. б. милләт мәнфәгатьләренә акча кызганмаулары белән халык хәтеренә кереп калган.

● Фазыл Әгъләмов, Илдар Кыямов һәм Миндар Әгъләмов.

Хәзер дә байларыбыз бар анысы, кайберләренең исемнәрен «Форбс» исемлекләрендә күреп тә куанабыз, тик милләт мәнфәгатьләре өчен мал түккәннәре генә ишетелми. Шулай да, хәләл малларын хәйрия эшенә кызганмыйча сарыф итүче гаярь ирләр дә табыла. Алар трибуналардан ялкынлы нотыклар сөйләмичә генә, җиргә нык басып үз эшләрен алып бара, туып-үскән авылларын кайгырта, мәчетләр төзи, чит кавем арасында татарның дәрәҗәсен саклап яши. Миндар Әгъзам улы Әгъләмов – шундый асыл затларның берсе. Бертуган Фазыл абыйсы белән ул җитәкләгән «Техтранссервис» оешмасы Себердә генә түгел, бөтен Россиягә билгеле. Оешма Ханты-Манси һәм Ямал-Ненец округларындагы эреле-ваклы 1500 дән артык предприятиене, «Сургутнефтегаз», «Газпром», «Роснефть», «Төмәнэнерго», «Лукойл-Көнбатыш Себер» кебек зур берләшмәләрне машина һәм тракторлар өчен запас частьләр, җиһазлар белән тәэмин итеп тора. Оешманың «Автогалактика» кибетләр челтәре Себернең байтак шәһәрләрендә эшли.

Миндар Чирмешән районының Әмир авылында Әгъзаметдин абзый белән Мөшбикә апа гаиләсендә җиденче бала булып дөньяга килә. Сугыштан яраланып кайткан әтиләре төпчегенә 11 яшь чагында дөнья куя, абый-апалары белән бергәләп ул тормыш арбасын тартуга бик яштән җигелә. Әниләре аларга әти дә, әни дә була – малайларны шуклыклары өчен тотып ярырга да күп сорап тормый. Мөшбикә апа балаларын кечкенәдән «Бердәм булыгыз. Бергә булсагыз гына көчле булырсыз!» – дип үстерә. Әтиләре урынына калган Әмир абыйлары сүзен тыңлап, егет 1977 елда Казан авиация институтына керә. Татар авылыннан чыккан Миндарга техник уку йортында укып китү җиңел булмый, ләкин институтны ул яхшы билгеләр белән тәмамлый. Аннары яңа гына финанс институтын тәмамлаган хатыны Гөлфия белән Себергә чыгып китә. Адәм баласы рәхәт тормыштан Себергә китми, Миндар да хәерчелектән кача. Берничә ел эшләп, машина, фатир алырлык, аякка басарлык акча эшләп кайту була исәбе. Тик язмыш дигәнең аның Себердә җыяр ризыкларын мулдан язган булып чыга. Хәер, аларның нәселе бу кырыс якларны күптән үз иткән була инде – Асия апалары белән Фәрхәт җизниләре Себергә 1974 елда ук килеп урнаша, соңрак килгән энекәшләре Фазылга да, Миндарга да ныклы таяныч булалар. Миндар Себер нефтьчеләре башкаласы булган Сургутның транспорт идарәсенә гади механик булып эшкә урнаша. Тырышлыгын, төгәллеген күреп, ай ярым эчендә ремонт-механика остаханәсенә мастер итеп куялар. Озак та үтми, Сургуттан 30 чакрым ераклыкта яңа база ачалар, тик анда производствоны торгызуда җитәкче булырга берәү дә ашкынып тормый. Миндар тәвәккәлли – эштән дә курыкмый, тырышлыгы да җитәрлек. Биш ел буе юктан башлап базаны төзергә, өч кешенең берсе элеккеге зэк булган коллективны туплап, җитәкчелек итәргә туры килә. Гади мастердан оешманың баш инженеры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә, мең ярымлык коллектив белән җитәкчелек итә. «Сургутнефтегаз»да эшләгән елларында үз эшенең чын остасына әверелә.

Ул арада миллионнарның тормышын үзгәрткән 90 нчы еллар килеп җитә. Фазыл абыйсы, хатыннары белән утырып сөйләшәләр дә, тәвәккәлләп үз эшләрен ачарга дигән карарга киләләр. Эш башларлык зур акчалар юк, тик һәркайсында «Сургутнефтегаз»ның акцияләре бар. Дүрт комплект акцияне саткач, беренчел капиталга җитәрлек акча барлыкка килә. Нәрсә белән шөгыльләнергә соң? Барысы да тимер өлкәсен шәп белә. Халыкның «Тимерле кеше тилмермәс» дигән мәкален искә алалар да, тәвәккәллиләр. «Сургутнефтегаз»ның зур киңәшмәләрендә утырганда, Миндар кайсы оешманың нинди проблемасы барлыгын акрын гына язып утыра да абыйсына хәбәр итә. Фазыл абыйсы исә шул предприятиеләрне йөреп, заказлар җыя һәм барлык кирәкле запчастьләрне, җиһазларны кайтарып та бирә. 2000 елда Миндар «Сургутнефтегаз»дан тулысынча китә һәм шуннан бирле 23 ел буена алар абыйсы белән үз эшләрен алып баралар. Ике ел буе табылган барлык керем бизнеска сарыф ителә, чөнки күп нәрсәне төзергә, булдырырга кирәк. Бүген оешма «Урал», «ВАЗ», «УАЗ» кебек 23 заводның дилеры булып тора, анда 250дән артык кеше эшли. Идарә эшенә Фазыл абыйларының кызы Рамилә һәм Миндар абыйның улы Айдар да килеп кушылган. Алар турында өлкәннәр: «Фикер йөртүләре яңача, гаделлек белән эшлиләр», – ди.

Дөньяның теләсә кайсы почмагына барып ял итү мөмкинлекләре булса да, Әгъләмовлар өчен иң сөеп кайта торган урыннары – туган авыллары Әмир. Миндар абыйның хыялы – авылларын яшәтү. Авыл көне, Сабан туйлары мул бүләкләр белән зурлап үткәрү, мәктәпкә, балалар бакчасына даими ярдәм – барысы да хыялны тормышка ашыру юлындагы адымнар лабаса. Бертуган Әгъләмовлар җиде ел буе авылда туган һәр балага 100 мең акча бүләк итеп килә. Моның максаты – яшь киленнәрне күбрәк бала табарга кызыктыру. Үз авылларының тарихын барлап, искиткеч затлы, бай мәгълүматлы «Мәңге яшә, Әмирем!» дип аталган кирпеч калынлыгындагы китапны да Әгъләмовлар чыгарткан. Узган ел эшмәкәрләр авылдашларына бәйрәм ясап, бу китапны һәр йортка бүләк итте. Иллесен тутырган авылдашларына юбилейларында зур бүләкләр биреп котлауны да гадәткә керткәннәр. Сугыш чоры балаларына – 1945 елгача туган авылдашларының пенсиясенә һәр айны икешәр мең өстәмә түләп торулары да – авыл өчен кылган игелекләренең бер өлеше.

Әгъләмовлар Әмирдәге түбәсеннән су үтә башлаган мәчетне дә, подвал ясап, яңа манара куеп, янкорма белән өр-яңадан эшләтә. Авыл халкының ризалыгы белән мәчеткә әтиләренең исемен, «Әгъзам» дип кушалар. Җиде баласына тәрбия биргән әниләре Мөшбикә хөрмәтенә дә мәчет төзиләр. Анысының тарихы болай. Ел ахырында оешманың хисабында планлаштырылмаган керемнән күпмедер акча кала. Нишләтергә? Хатыннары беравыздан: «Мәчет салдырыйк!» – ди. Шулчак кинәт авылдагы Әмир абыйлары шалтырата. «Энекәшләр, бер зур гамәл кылып калдырыгыз, – ди ул, – мәчет салыгыз!..» Дөрес, теге акча гына җитми бу эшкә, тик тырышлык белән яхшы материаллардан, шәп белгечләр чакыртып, Аллаһ йортын өч ел эчендә төзетеп чыгалар. Чирмешәндәге «Мөшбикә» мәчете бүген җөмһүриятебездәге иң күркәм, затлы мәчетләрнең берсе санала.

Миндар абый үзе исә Татарстаннан Себергә килгән татарларны эшле итүен – милләт өчен иң зур игелеге, дип саный. Әгъләмовлар Татарстаннан килгән йөзләгән яшь кешене укытып эшкә өйрәткән, үз һөнәрләрендә профессионал ясаган. Алар аякка басып, өйләнеп, гаилә корган. Оешмада төрле милләт вәкилләре эшләсә дә, аларны Себердә «Татарлар фирмасы» дип йөртәләр. «Ничек хәлләр?» дип сорасаң, урысы, татары, хохолы, чувашы да «Аллага шөкер!» дип җавап бирә. Шөкер итәрсең дә: барлык хезмәткәрләр бушлай туклана, 44 көн түләүле отпуск ала, хезмәт хаклары яхшы булгач, ярты ел эшләүгә ипотекага фатир алалар. Коллективта ике-өч фатир алучылар да бар. Аракы эчү юк. Дөрес, барлык өлкәләрдә дә күзәтелгән кадрлар җитмәүчелеге Миндар абыйның да борчый. «Эш сораучылар күп, ә эшләрлек кеше юк, – ди ул. – Кемнеңдер үтенечен тыңлап, кешене эшкә аласың, атна-ун көн йөри дә, монда бит эшләргә кирәк икән, диләр. Җыелышларда да гел әйтәм: яхшы яшәү өчен күп эшләргә кирәк! Бездә хәерчелектән аптыраган кеше өчен тырышлык белән күтәрелү мөмкинлеге бар».

Сер түгел, хәзер илдә һөнәри белем бирүнең сыйфаты төште. Әгъләмовлар бу эшне дә үзләре хәл итәргә алынган. Әйтик, авылдан берниндн белеме булмаган егетне эшкә кабул итәләр, хезмәт хакы билгеләләр дә, әйтәләр: менә сиңа 8 имтихан, машина төзелеше, майлар һ.б. темалар буенча һәр имтиханны тапшырган саен, хезмәт хакың арта барачак. Һәр шимбә – белем көне, оешманың барлык предприятиеләрендә (Ханты-Мансийск, Ноябрьск, Когалым, Нефтеюганск) дәресләр бара. Трансмиссияме ул, металлмы – берәр егет алдан әзерләнеп, доклад ясый. Яшь кеше киң аудитория алдында сөйләргә, техник терминнар кулланырга өйрәнә, үз фикерен әйтә, тәҗрибә туплый. Нихәтле тәҗрибә ала яшь кеше: беренчедән, кеше алдында сөйләргә, фикер әйтергә өйрәнә, икенчедән, техник терминнарны кулланырга, аңларга өйрәнә... Сигез имтиханны да тапшыргач, егетнең хезмәт хакы ике тапкырга диярлек арта. Шушы ысул белән кадрлар әзерләп тә, бу татар эшкуарлары дәүләткә күпме файда китерә!..

Татарстанның уңышлары өчен сөенеп, җитешмәгән яклары өчен көенеп яши торган шәхес ул Миндар абый. Казанда чыккан татар матбугатын укырга, Камал театрының һәр премьерасына гаиләләре белән барып кайтырга да вакыт таба. Калебендә милләт гамен саклаган ат уйнатыр ир солтаннары табылу татарның киләчәгенә булган өметне сакларга да ярдәм итә…

Эльмира СИРАҖИ.

Әллә файдалы, әллә юк

Британия галимнәре 1935 елда медицина тикшеренүендә катнашкан гражданнарны эзләп тапкан. Аларның балачакта сөт һәм сөт ризыкларын күбрәк кулланганнарының сәламәтлеге яхшырак булуы ачыкланган. Киң таралган ялгыш фикергә карамастан, майлы сөт йөрәк авырулары килеп чыгу куркынычын арттырмый икән. Киресенчә, көненә чирек литр сөт эчү йөрәк өянәгеннән үлеп китү ихтималын 60 процентка киметә. Шуңа күрә галимнәр мәктәптә барлык балаларга да бушлай сөт эчертергә кирәк, дип саный. Өлкәннәр исә тәүлегенә 1 стакан табигый сөт эчәргә (порошоктан ясалганын түгел!) яки 1 стакан йогурт белән сыр кисәге ашап куярга тиеш. Бу организмның кальцийга булган ихтыяҗын канәгатьләндерәчәк. Ә кальций кан басымын төшерә һәм йөрәкнең кан белән тәэмин ителүен яхшырта. Сөттәге инсулинга охшаган гормонның организмда җитәрлек кадәр булуы йөрәк чирләре куркынычын киметә дә инде. Әмма сөтнең организмга тәэсирен өйрәнү шактый катлаулы эш. Табибләр ике төркемгә бүленә. Кайберләре сөт хәтта яман шештән саклый, дип ышанса, икенчеләре нәкъ киресен исбатлый. Шунлыктан сөтне дә чамасын белеп кенә куллану хәерле.

(“Fishki.net”).

Агартып кына калмый

Дөньяда иң күп кулланыла торган азык өстәмәләреннән берсе – титан диоксиды Е171 – сәламәтлек өчен зыянлы. Ул идеаль агарткыч санала, аны икмәккә, сөт һәм кондитер ризыкларына, сагызга, теш пастасына кушалар. Ә иң куркынычы – титан коры сөт җитештерүдә кулланыла, аңардан исә бик күп сөт ризыгы әзерләнә. Мондый ризыклар составында титан диоксиды хәтта күрсәтелми дә. Күптән түгел галимнәр ачыклаганча, Е171 ашказаны һәм эчәклек күзәнәкләре структурасын җимерә, бу исә куркыныч бактерияләргә ашкайнату системасына үтеп керергә мөмкинлек бирә, шул ук вакытта цинк, тимер, май кислоталары кебек мөһим матдәләрнең үзләштерелүенә комачаулый. Француз галимнәре әйтүенчә, сынау барышында титан диоксидын даими кулланган хайваннарның 40 процентының ашказанында яман шеш пәйда булган. Россиядә Е171 өстәмәсен ашамлык җитештерүдә куллану рөхсәт ителгән, сәламәтлеккә зыян китермәслек тәүлеклек норма исә ачыкланмаган. Шунлыктан коры сөт җитештерүче үз продуктына теләсә күпме титан диоксиды куша ала.

(“Лента.ру”).

Кояш каласы

Латвиянең Цесис шәһәре янында миллионер Айварс Звирбулис үзенең фантастик проектын тормышка ашырган: калкулыклы урындагы 30 мең гектар урманны сатып алып, ул “Кояш каласы” төзегән. Анда кешеләр махсус кагыйдәләр буенча яши. Территориядәге 300 йортның барысы да экологик чиста материалдан салынган. Һәр йортка 0,4тән 1,3 гектарга кадәр мәйданлы кишәрлек беркетелгән, анда кечкенә генә күл һәм урман бар. Аматциемста бөтен йортлар нарат һәм чыршыларга зыян китермичә махсус техника ярдәмендә бик астан үткәрелгән үзәк канализация, югары тизлекле Интернет һәм электр энергиясе белән тәэмин ителгән. Һәр йортта 90-100 метр тирәнлектәге скважиналы геотермаль җылылык насосы бар, ул җир энергиясен җылылык энергиясенә әйләндерә. Әлеге энергия йортны җылытырга да, суны кайнарлатырга да җитә. Бик салкын кышкы көннәрдә генә камин ягарга кирәк була. Бер йорттан да икенчесе күренми. Урман каласында коймa-читәннәр юк, җәнлек-җанварлар рәхәтләнеп йөри ала. Өреп, кыргый хайваннарны куркытмасын өчен, бәйдә эт тоту тыела, аны өйдә генә асрарга мөмкин. Кич һәм төнлә урамда каты тавышланырга ярамый. Әлеге кала кеше һәм табигатьнең гармониядә яши алуына менә дигән мисал булып тора.

(“Интересно.cc”).

Үзебез агуланабыз

Дөньяда миллионлаган кеше репеллент куллана – бөҗәкләрне куркытыр өчен өстенә көчле исле матдә сиптерә. Шул вакытта үзенең дә искиткеч куәтле нейротоксин агымы астында калуы турында исә уйланмый. Франция тикшеренүчеләре черкигә каршы агу составына керә торган химик матдә – диэтилтолуамидның кеше өчен дә гаять агулы булуын ачыклаган. Нерв системасы эшчәнлеге өчен иң әһәмиятле энзимны камап алып, диэтилтолуамид баш мие эшчәнлегенә комачаулый һәм өянәк, тартышулар китереп чыгара. Шунлыктан галимнәр, спрей составында әлеге матдә микъдары 50 проценттан артып китсә, мондый репеллентны кулланудан тыелырга киңәш бирә.

(“Daily Mail”).

